Мөнәвир Фазлыев

# Сандугачлы илкәем



Мөнәвир Фазлыев

# САНДУГАЧЛЫ ИЛКӘЕМ



*Шигырьләр,*
*җырлар, поэмалар,*
*кыска хикәяләр*

Уфа
2004

УДК 821.512.145
ББК 84 (2Рос-Тат)
Ф 16

Ф 16 **Мөнәвир Фазлыев**. Илкәем бар. — Шигырьләр, җырлар, поэмалар, кыска хикәяләр. — Уфа, полиграфкомбинат, 192 бит.

ISBN 5-85051-315-9

Яңавыл районыннан талантлы каләм иясе Мөнәвир Фазлыевның юбилей уңае белән нәшер ителгән бу җыентыгына иң популяр җырлары, төрле елларда язылган шигырьләре, «Утлы елларда» һәм «Мәхәббәткә мәдхия» дигән поэмалары, фәһемле чәчмә әсәрләре кертелде.

ISBN 5-85051-315-9 © Мөнәвир Фазлыев, 2004

## Үзем хакында сүзем

Мин 1934 елның 7 апрелендә Яңавыл районының Истәк авылында туганмын. Яңавылда урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем алдым. Диплом эшем «Шәехзадә Бабичның иҗатында юмор һәм сатира» дигән тема иде. Ш. Бабичның әсәрләрен күпсанлы архив материалларыннан җыеп, туплап, аңлатмалар биреп, 1958 елда Казанда бастырып чыгардык. Филология фәннәре докторы, профессор, кафедра мөдире Хатип ага Госман бу юнәлештә зур эш башкарды, җыентыкка эчтәлекле кереш сүзне дә ул язды. Бу китапның әһәмиятен аңлатып торуның кирәге юктыр, мөгаен. Тик шуны әйтеп үтәсем килә: Ш.Бабичның әсәрләре утыз алты ел буена китап булып басылып чыкмаган, халык бу зур әдипнең әсәрләрен укудан һәм өйрәнүдән мәхрүм ителгән иде.

Кечкенәдән әдәбиятны, театрны яраттым. Үзем дә үзешчән сәхнәләрдә концертларда, спектакльләрдә катнаштым. Башлангыч сыйныфларда ук ши-

гырьләр яза идем. Моның сәбәпләре бик җитди: Газимә һәм Нәгыймә апамнар бер-бер артлы почтальон булып эшләделәр. Алар алып кайткан гәзит-журналлар белән укып таныша һәм кайбер әсәрләрне ятлый торган идем.

Аеруча әниемә, әтиемә рәхмәтлемен. Алар сәнгатьне сөйде һәм безне дә нәфислеккә җәлеп итәргә тырышты. Алардан «Сак-Сок» бәетен, «Ахырзаман», «Мәүлит» һәм башка халык әсәрләрен тыңлап үстем. Әнием укырга, язарга белә иде. Туксан өч яшендә, үләреннән берничә көн алда, «Картлык көннәре» дигән мөнәҗәтен көйләп ишеттерде.

Хәләл җефетем Рәшидә Закирҗан кызы белән бер үк уку йортын тәмамлап, һәрвакыт бергә-бергә тормыш һәм сәнгать юлыннан атлыйбыз.

Туганнарым да, балаларым да җырга, биюгә, әдәбиятка мөкиббән гашыйк.

Университетта укыганда һәм хәзер гәзитләргә язышам. Район гәзите редакциясендә эшләп алдым. 23 ел Истәк урта мәктәбе директоры, шуннан соң авыл советы рәисе булдым. Русия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы исеменә лаек булдым, тел һәм әдәбият, тарих укытучысы булып эшләдем. Бүгенге көндә туган мәктәбемдә тарих укытам.

Шигырьләрем район гәзитендә, «Кызыл таң», «Өмет», «Башкортстан укытучысы» журналында, «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан» һәм балалар гәзитләрендә басылды. 2000 елда Казанда «Агым сулар» дигән китабым дөнья күрде, шигырьләр шәлкемем Уфада, Башкортстан «Китап» нәшриятында «Акчарлак» альманахында басылды, 2003 елда балалар өчен шигырьләрем шушы нәшриятта «Колыннар, колынкайлар» дигән аерым җыентык булып нәшер ителде.

Берничә шигыремә үзешчән композиторлар көй яздылар. В. Хәбисламовның «Тепловоз» дигән шигыремә язган көе иң озын гомерлесе булды. Яңавыл сәнгать мәктәбе укытучысы Г. Зыязова, Ямады урта мәктәбе укытучысы Р. Исламов, Яңавыл өченче санлы урта мәктәбе эшчесе М. Вәҗетдинов та шигырьләремә көй иҗат иттеләр.

Ә бу китабымның нәшер ителү тарихы болай. Укучыларым беркөнне Истәк авыл советы бинасына җыелдылар да, шундый карарга килделәр:

— Укытучы абыебызның тиздән җитмеш яшьлек юбилее. Без аңа нинди ярдәм күрсәтә алабыз? Аның ике китабы дөнья күрде Казанда һәм Уфада. Өченчесе чират көтеп ята. Әйдәгез, шул китапны чыгаруны тизләтик: үзе исән чакта китабын үзе кулына алып укысын, без дә укырбыз. Матди ярдәм күрсәтик, — диделәр.

Хәзерге заманда акча кадерле (артык акча беркемдә дә юк). «Шуны белә торып, укучыларыңнан акча алырга ничек кыюлыгың җитте?» — дип сорарсыз, бәлки. Йөрәгем белән каршы торсам да, мине үгетләп җиңделәр.

— Хәзер социализмда түгел, капитализмда яшибез, спонсорлык итү дигән сүз бу, яки меценатлык була, — диделәр.

Менә кемнәр алар минем спонсорларым:

1. Зәйдуллин Роберт Сөләйман улы, район кулланучылар җәмгыяте Советы рәисе, кулланучылар кооперациясе отличнигы, Башкортстан Республикасының атказанган сәүдә хезмәткәре.

2. Минигалиев Радик Нарислам улы, район юл ремонтлау һәм төзү идарәсе начальнигы.

3. Нурисламова Илүсә Мәгафур кызы — эшкуар.

4. Салихов Алим Барый улы – Яңавыл май-сыр комбинатының генераль директоры, атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре.

5. Салихов Илдар Барый улы – район элемтә бүлеге җитәкчесе, Башкортстан Республикасының Почет грамотасы белән бүләкләнгән.

6. Харисов Фәрит Фахраз улы – Яңавыл И. Моксинов исемендәге гимназия директоры, Халык мәгарифе отличнигы.

7. Шакиров Фәрит Мөхәммәтнур улы – «Краснохолмнефть» НГДУ начальнигы урынбасары.

8. Шакиров Өлфәт Мөхәммәтнур улы – элеваторның прорабы.

9. Хәбибуллин Финаз Фоат улы – М. Горький исемендәге колхоз рәисе.

10. Гыйльмиев Салават Нәзир улы – торак-коммунал хуҗалыгының баш инженеры.

Алар мәктәпнең генә түгел, районның горурлыгы. Район оешмалары һәм хуҗалыкларында җитәкче урыннарда зур эш башкаралар. Сау-сәламәт булсыннар, рәхмәтем зур аларга. Эшләрендә зур уңышлар, гаилә бәхете телим. Амин.

*Богау-чылбырны өзәрлек җегәрем бар,*
*Явызлыкларны җиңәрлек йөрәгем бар.*
*Күңелләрне күтәрерлек җырларым бар,*
*Халкым белән бергә ярган юлларым бар.*

# ШИГЫРЬЛӘР

## ЯГЕЗ, АВЫЗ ИТИК

Кулларыма ярсып каләм алам,
Үзем язам, үзем тартынам;
Дуслар әйтеп бетермәгән хисләр,
Ашкынулар миндә бар сыман.

Акыл көче хисләр ташкыныннан
Булгангамы әллә көчлерәк,
Өлгергән күп җимеш арасында
Минекеләр яшел төслерәк.

Өлгерсен, дип, кәгазьләргә төреп,
Шүрлекләргә куйдым тутырып.
Файдасы шул булды: шүрлек сынды,
Күбе бетте изелеп, сытылып.

Пешкәннәрен, исән калганнарын
Сайлый-сайлый гомер кичердем.
Җимешләрдән, ягез, авыз итик,
Хөкемегезгә сезнең китердем.

## КИТМӘС ИНДЕ

Китми яннан, кит инде, кит,
Дип кусам да,
Бакчалардан өйгә кереп
Утырсам да;

Гөрләп аккан чишмә җырын
Тыңласам да,
Җилгә каршы йөзем куеп
Тын калсам да;

Китми яннан ялынсам да,
Ялварсам да,
Онытыйм, дип, өзгәләнеп
Ялгансам да.

Китмәс инде, мәхәббәтнең
Чыны шулдыр.
Каләм җаным, сиңа ирек —
Җырлар тудыр.

## ИЛКӘЕМ БАР

Илкәем бар, телкәем бар.
Мин түгел үксез бала.
Җырлап яшим, милләтемнән
Дәртле моң ала-ала.

Дусларым бар, кошларым бар,
Мин түгел ялгыз бала.

Күңелемнең күкләрендә
Өмет йолдызым яна.

Авылым бар, саулыгым бар,
Мин түгел көчсез бала.
Халкым белән бергә атлыйм
Яңа юл яра-яра.

Җисемем бар, исемем бар,
Мин түгел атсыз бала.
Татар каны кайный миндә,
Минме соң затсыз бала?!

## БАШКОРТСТАН

Башкортстан — иген иккән җир,
Салаватлар гомер иткән җир.
Ата-анам мине тапкан җир,
Авызыма икмәк капкан җир.

Йолдыз, Кояш көнгә баккан җир,
Агыйделкәй көлеп аккан җир,
Аргамаклар ярсып чапкан җир,
Муллык, байлык тулып яткан җир.

Урманнары сөрмә тарткан җир,
Уралкаем күккә ашкан җир,
Оҗмахлардай матур җиркәем,
Имин яшә, туган илкәем!

## КУАНАМ МИН

Язгы җылы җилләр
Назлады күңелне.
Газиз туган җирем
Чәчәккә күмелде.

Канатланды гомер,
Кошлар кайткач илгә.
Яшәрде киң кырлар,
Тамчы тамгач җиргә.

Куанам мин бөтен
Дөнья белән бергә.
Күк күгәрчен, син дә
Гөрлә әйдә, гөрлә.

## КОШЛАР КАЙТА

Кошлар кайта безнең якка,
Ишеттем тавышларын.
Маңгаема кулым куеп,
Шатланып каршыладым.

Якын дусларымны күргәч,
Яшь килде күзләремә.
Язлар безне очраштыра,
Аера көзләр генә.

Туктагызчы, очмагызчы,
Баш өстемдә торыгыз.

Җилкендереп йөрәгемне,
Тагын бер кычкырыгыз.

Рәхмәт сезгә, илебезгә
Исән-сау кайткан өчен.
Сабыйлар кебек сөенәм
Дусларым арткан өчен.

## ИСТӘГЕМ

Сиреньнәр чәчәк атканда
Яратам хуш исләрен.
Син — минем тере чәчәгем,
Туган авылым Истәгем.

Кушымта:

Ераклардан балкып тора,
Ни җитә Истәгемә.
Сөйкемле авылдашларым
Һәрвакыт истә генә.

Сандугачлар белә икән
Кайда оя корырга,
Кайтмаслар иде сагынып
Авылыма турыга.

Кушымта.

Дәртем таша, көчем арта
Синдә, авылым — җаным.

Синдә минем мәхәббәтем,
Сөеп туймаслык ярым.

Кушымта:

Ераклардан балкып күренә,
Ни җитә Истәгемә.
Сөйкемле авылдашларым
Һәрвакыт истә генә.

## БЕЗ – ЯҢАВЫЛ ЯКЛАРЫ

Яшьләргә дә, картларга да
Сәламәтлек зур байлык.
Байлыгыбыз бар чагында
Биеп тә җырлап калыйк.

Без Мөхәммәт Идрисләрнең
Ватандаш туганнары.
Өздереп басканда очкын
Чәчрәтә торганнары.

Йөрәкләрнең ялкынланып,
Дөрләп янган чаклары.
Тыпырдатып басыйк әле,
Без – Яңавыл яклары.

Аякларың кәкре булса,
Бии-бии төзәлер.
Матур кызлар шома басып,
Үзәкләрне өзәдер.

Егет егет буламыни
Килештереп басмаса?
Орчык кебек бөтерелеп,
Кызлар күңелен ачмаса?

Яңавылда җыр сөймәгән,
Биемәгән кеше юк.
Безнең яшьләр алтын куллы,
Эшләмәгән эше юк.

Эше барның ашы бар шул,
Туфлиемнең башы тар.
Аякларым да җәл түгел,
Биик әле, асыл яр!

## ЭЗЛИМ

Тукайны эзләп таптым мин,
Укып Бабич китабын.
Бабич канатын ныгыткан
Бакчасында Тукайның.

Олы шәхесләрне таптым,
Эзлим хәзер үземне.
Халкым нәрсә дияр икән,
Әйтсәм йөрәк сүземне?

Ничә еллар шул сорауга
Җавап эзләп баш ватам.
Тауга карасам, тау биек,
Тауга шүрләп күз атам.

Әйтә йөрәк: «Икеләнмә,
Башла бисмилла итеп.
Тырыш ташка кадак кага,
Чыга чүлләрне үтеп.

Кайнар йөрәгең типкәнгә
Бары тик куан гына,
Гигантлар арасында син
Булсаң да гном гына».

## ҖЫРЛАР ОЧЫРАМ ӘЛЕ

Җил канатына утыртып,
Җырлар очырам әле.
Кайчан да бер юлларында
Бәлки, очрарлар әле.

Җил тынып торган арада
Алалсаң иде тотып,
Күңелләреңә хуш килеп,
Калалсаң иде отып.

Ефәктәй сарылса иде
Тынгысыз йөрәгеңә,
Былбыллар булып сайрасын
Күңелең тирәгендә.

Оч син, җырым, еракларга,
Эзләсәң дус табыла;
Янгыра урман-кырларда,
Бәйрәмдә, һәр табында.

Йөрәктән чыккан җыр гына
Йөрәккә ята, диләр.
Үзенә дус-ишләр табып,
Әйләнеп кайта, диләр.

## ҖӘЙГЕ ТАҢ

И, кошларым, мин үземне
Арагызда хис итәм.
Җырларыгызга мавыгып,
Сизмәдем дә — кич җиткән.

Карасана, төн авышкан,
Якты таң туып килә.
Ерактан сагынып кайткан
Сандугач концерт бирә.

И, сайрады, и, сайрады,
Үзәкләремне өзеп.
Тыңладым моңлы тавышын,
Еламыйча чак түзеп.

Осталыкны асыл кошка
Биргәч тә биргән Ходай.
Дөнья ничек булыр иде
Бар да сайраса шулай!

Сандугач сайрап туктады —
Ял кирәк асыл кошка.
Чыпчыклар хоры җыр башлый,
Аларның җыры кыска.

Таң йокысыннан уянып,
Әтәч кычкырды сузып.
Самолет очты еракка
Күккә аксыл юл сызып.

Көтүче колга шартлатты
Авыл башына чыгып.
Көтүлеккә алып төште
Мал-туарларны җыеп.

Әнә Кояш күтәрелә
Пешкән зур алма кебек.
Баласын — Җирне кочаклап,
Елмая ана кебек.

Күңелемдә канат үсә
Күреп кошлар очканын.
Җырым да син, нурым да син,
Гүзәл Башкортстаным!

## ЧИШМӘКӘЙ

Чишмәкәй, мин мәңге гашыйк сиңа,
Җырларыңа, салкын суыңа.
Борма-борма көмеш юлларында
Уйнаклаган кояш нурына.

Юмартсың син, Туган җирем кебек,
Моңлысың син, сайрар кош сыман.
Дәртлесең дә үзең, татлысың да,
Буйга җиткән сылу кыз сыман.

Җырлый-җырлый ага тонык сулар,
Алы да юк аның, ялы да.
Чишмә сукайлары ширбәтләнә,
Сөйгән ярым булса янымда.

## ЯРАТАМ МИН ТУГАН АВЫЛЫМНЫ

Яратам мин туган авылымны,
Шунда туып, шунда үскәнгә.
Сусаганда салкын чишмәләрнең
Учлап-учлап суын эчкәнгә.

Яратам мин сабантуйларында
Гармуннарга кушылып җырларга.
Сөйгән ярым белән таңга кадәр
Сандугачның моңын тыңларга.

Яратам мин туган авылымны,
Әнкәм кебек бердәнберемне.
Мин бәхетле булыр идеммени,
Алыштырсам газиз җиремне.

## НУРЛЫ ИДЕ ЯШЬЛЕГЕМ

Уйный алмый җил таратып,
Сирәкләнде чәчләрем.
Яшьлегемне сагынганда
Тәгәри күз яшьләрем.

Салават күпере кебек
Нурлы иде яшьлегем.
Баерга барса да гомер,
Күңелем гел яшь минем.

Болыннарда колыннардай
Уйнадым сикереп, чабып.
Яндым, көйдем, күмерләндем,
Үземә тиң яр табып.

Яшьлегемдә юл сапканмын
Картлыкка барыр өчен.
Оҗмах дигән мәңгелектә
Ялгызым калыр өчен.

Тукта, тукта, бер минутка,
Ташлап китмә, яшьлегем.
Картлыгым килә бастырып,
Күләгәңә яшеренім.

## ЯҢАВЫЛ ПЛЮС КАЗАН

Яңавыл — Казан арасын
Җырлап кына барасы.
Сөйгән ярым Казан кызы,
Мин — Яңавыл баласы.

Кушымта:

Машина тәгәрмәчләре
Тик бер җыр җырлый һаман:

Яңавыл плюс Казан да,
Яңавыл плюс Казан.

Яңавыл — Казан арасын
Поездлар шаулап үтә.
Үлərдәй булып сөйгәнем,
Мине сагынып көтә.

Кушымта.

Машина тәгәрмәчләре
Майламасаң, әйләнми.
Сагынганда, саргайганда
Бер күрүе әллә ни.

Кушымта.

## КИТМӘГЕЗ, КЫЗЛАР

Китмәгез, кызлар, китмәгез,
Чит җирләрдә авыр бит.
Сезнең туган мәркәзегез
Шәһәр түгел, авыл бит.

Авыл ямен, суның тәмен
Алып китәсез инде.
Сөлек кебек егетләрне
Ялгыз итәсез инде.

Туган җирен, сөйгән авылын
Ярата кайсыбыз да.
Гомергә торып калыгыз,
Кунакка кайтыгыз да.

## ОНЫТМАГЫЗ ХАТЛАР ЯЗАРГА

Истәкләрдән Казан күренә икән —
Зәңгәр экраннарга карасаң.
Калдыгыз ич, энекәшләр, Казанда,
Онытмагыз безгә хатлар язарга.

Зәңгәр экранда тик сурәт кенә,
Үзегезне бик күрәсебез килә.
Калдыгыз ич, энекәшләр, Казанда,
Онытмагыз безгә хатлар язарга.

Сагышлардан саргаермын ахыры,
Казаннарга әгәр үзем бармасам.
Калдыгыз ич, энекәшләр, Казанда,
Онытмагыз безгә хатлар язарга.

Без сагына диеп, борчылып, кайгырып,
Китмәгез мәшһүр Казаннан аерылып.
Калсагыз да, энекәшләр, Казанда,
Онытмагыз безгә сәлам язарга.

Зәңгәр экран ул бары сурәт кенә,
Сурәт түгел, үзегез кирәк миңа...

## САГЫНАМ

Гомер үткән саен әллә нигә
Казанымны өзелеп сагынам.
Йөрәкләрем өзелеп төшәр сыман
Поезд китсә Казан ягына.

Их, барасым килә ак шәһәргә
Йомшак вагоннарга утырып.
Карар идем иркә гөлләренә
Яшьле күзләремне тутырып.

Без укыган белем сарайлары
Көтәләрдер кебек һаман да.
Сабакташлар белән чират торып
Имтиханнар бирдек без анда.

Кино-театрлар каршылады
Яшь парларны, сөйгән ярларны.
Кызлар бүлмәсендә, уйнап-көлеп,
Тамак ялгап алдык аннары.

Анда яши дуслык, татар рухы,
Тукай теле, татар намусы.
Яңгырый анда безнең милли җырлар,
Болгар бабамнарның сагышы.

...Поезд китте Казан якларына,
Хисләр җәя кебек тартылган.
Вагоннарга төяп сагышымны,
Озата бардым поезд артыннан.

## СҮЗЛӘР — ГӘРӘБӘ

Хисләрем — диңгез,
Каләмем — ишкәк.
Корабым — авылым,
Ул була — Истәк.

Өметем татлы,
Теләгем — пакьлек,
Йөрим өләшеп
Күңелгә шатлык.

Фикер — алтын җеп,
Сүзләр — гәрәбә.
Тезсәң әгәр дә
Охшар кәрәзгә.

## НИЧЕК КИТИМ

Йөгерешеп килә шигырьләрем:
Йөрәгеңә безне ал, диләр.
Милләтемә ишеттергәнеңә
Авызыңа бал да май, диләр.

Китмә, зинһар, бездән аерылып,
Безнең арабызда кал, диләр.
Сәйләп итеп кайнар хисләреңне
Шигырь юлларына сал, диләр.

Ничек итеп сезне ташлап китим,
Сездән башка яши алмам мин.
Халкым миңа тел ачкычы биргән,
Шул бүләккә тугры калам мин.

## КҮҢЕЛЕМ ЧИШМӘЛӘРЕ

Үткән гомер — өзелгән гөл,
Кабат яңармас инде.
Куера моң-сагышларым,
Җырсыз таралмас инде.

Күңелем көтә нәрсәдер,
Яңгыр көткән гөл кебек.
Үзе өчен түгел, иле өчен
Кайгыра ул ир-егет.

Иркәләп үстергән гөлем
Җилләрдә сынмас әле.
Күңелемнең чишмәләре
Чылтырар, тынмас әле.

## КАЙМАША

Каймаша коя Бүәгә,
Бүә төшә Камага.
Якын дуслар булыйк, дисәң,
Безнең якны чамала.

Карталардан эзләсәгез,
Күрми үтәрлек кенә.
Елгабызны, билбау итеп,
Урап сүтәрлек кенә.

Үзебезгә бик кадерле
Кечкенә Каймашабыз.
Җәй булса да, кыш булса да,
Без шунда кайнашабыз.

Малайлар, кызлар җыелып,
Коенабыз суында.
Көч-куәт, сихәтлек туплап,
Уйныйбыз киң болында.

Каймаша су буйларында
Чакырым саен авыллар.
Йөгереп менеп җитәрлек
Уң ягында тавы бар.

Көтүләре уртлап йөри
Үзәнендә елганың,
Текемләп җәйгән табигать
Яшел хәтфә юрганын.

Төньякка карап акса да,
Суы җылы, май гына.
Сабыйлар буй салсалар да,
Өлкәннәргә сай гына.

Бер тарая, бер киңәя
Борма-борма юллары.

Елгабызны күмеп китә
Язгы ташкын сулары.

Йөзләрем китә ачылып,
Самавырым кайнаса.
Рәхмәт әйтәм: мең яшә, дип,
Мәрхәмәтле Каймаша!

## САГЫНДЫМ ИСТӘГЕМНЕ

Авылыма кайтам әле,
Сагындым Истәгемне.
Күкрәкләремне иркәли
Таңнарда искән җиле.

Яр буенда яшел тугай,
Чык тама гөлләреннән.
Сагынганымны белерсез
Сандугач телләреннән.

Мин утырткан ак каеннар
Яшел шәл ябынгандыр.
Көтәләрдер юлга чыгып,
Алар да сагынгандыр.

Авылыма кайтам әле,
Истәгем — татар иле.
Каршылар авылдашларым,
Каршылар нечкә билем.

## КҮТӘРЕЛӘМ ЗӘҢГӘРҺАВАГА

Ия булып бөркет канатына,
Күтәреләм зәңгәр һавага.
Нинди хикмәт: менеп җиттем, дигәч,
Баш өстемдә болыт кабара.

Кара болытларны пыр туздырам,
Әйләнәм дә җилгә шулчакта.
Күктән Җирнең гүзәллеген күзләп,
Очам вакыт белән бер сафта.

Бизгәк тоткан кебек Җир тетрәнә
Яңа ракеталар шартласа,
Нәрсә булыр, түземлеген җуеп,
Орбитадан читкә атласа?

Вакыт тизлегеннән уз, күңелем,
Әйләнеп кайт барган җиреңнән.
Өзелмәсен туган Җир гомере
Кешеләрнең вәхшилегеннән.

## ТЕЛӘК

Һәр мөселманга кадерле
Изге рамазан ае.
Көне-төне теләк теләп,
Сызыла йөрәк маем.

Иманга килсен түрәләр,
Акыл бир, сабырлык бир.
Иминлек килсен дөньяга,
Көлгә әйләнмәсен җир.

Тукталсын сугыш Чечняда,
Телим Ходайдан сорап.
Үтермәгез бәндәләрне,
Ит турагычта турап.

Кайда соң кешелеклелек,
Гаделлек, намус, вөҗдан?
Үтерүчеләр, караклар
Коры чыгалар судан.

Сүнә якты өметләре
Пәһлевандай ирләрнең.
Тир түгеп тапкан акчасы
Кесәсендә кемнәрнең?

Талаш, ызгышудан башка
Эшегез юкмы әллә?
Ничек ил ныгысын инде
Шушы болганчык мәлдә?

И Ходаем, изге ай бит —
Якты рамазан ае.
Түгелмәсен канлы яшьләр,
Сызмасын йөрәк маем.

## КӨЗГЕ ГӨЛЛӘР

Сары яфракларны җил туздыра,
Кара көзләр җәйгән канатын.
Ә мин кырда җыям чәчәкләрне,
Кар астында туңып калмасын.

Куырылып салкын кырауларда,
Күшеккәннәр койма янгырда.
Хәлсезләнеп бөгелеп төшсәләр дә,
Тырышалар исән калырга.

Утырттым мин тулы савытларга,
Алып кайтып җылы өемә.
Терелгәнгә гөлкәй-сылукайлар,
Торып-торып күңелем сөенә.

Ятимнәр бит көзге гөлләр төсле,
Сагышланган яшьле күзләре.
Балаларын ташлаган аналар
Хәтерләтә кара көзләрне.

## КАРЧЫГА КУНГАН ИКӘН

Бөдрә талкаем сызлана,
Ботагы сынган икән.
Былбыл кунасы тирәккә
Карчыга кунган икән.

Моңнар тыңлап, күкрәп үскән
Тал да бирешә икән.

Туздырылган яфраклары
Сулып бөрешә икән.

И явыз кош, нигә кундың,
Җырчы кунасы талга?
Ирешергә теләдеңме
Былбыл ирешкән данга?

## ҖИЛ ЯЛ ИТӘ

Җил ял итә әле, ял итә,
Уенынан туеп туктаган.
Чәчәкләрнең кысып биленнән
Җир куенында ереп йоклаган.

Җил ял итә әле, ял итә,
Кузгалырга һич тә уйламый.
Шадралатып зәңгәр күл өстен
Дулкыннарны куып уйнамый.

Җил ял итә әле, ял итә,
Урыныннан торып йөгерми.
Урамнарда, тыкрык, юлларда
Тузан туздырганы күренми.

Җил ял итә әле, ял итә,
Котырынды кичә кич белән.
Бәлки, ул да тәүбә итәдер
Кыенсынып кылган эшеннән.

## КУРКАМ

Авырсам, дусларым
Кайгырыр, дип куркам,
Чөнки бар кешенең
Тормышлары уртак.

Боексам, дусларым
Борчылыр, дип куркам.
Чөнки бар шатлыклар,
Хәсрәтләр дә уртак.

Җырласам, дусларым
Ишетмәс, дип куркам.
Чөнки бар җырлар да,
Моң-сагыш та уртак.

## АК КАРЛАР

Карларның үз корабы бар:
Көтү-көтү болытлар.
Җиребезгә килешеп тора
Кардан теккән толыплар.

Җепләре энҗе-мәрҗәннән,
Җем-җем итә нурлары.
Кар кызының эшедер бу,
Оста икән куллары.

Күзнең явын ала кышның
Яктылыгы, киңлеге;
Ак туй күлмәкләрен кигән
Сылуларга тиңлеге.

Ак карлар сибеп болытлар
Агыла да агыла.
Гүя, карлар да сагынып
Кайта туган ягыма.

## ӨЗӘМ ИНДЕ

Юк, юк мин бу дөньялардан
Бернәрсә дә алып китмим.
Дөнья бит ул — бал шикелле,
Бер кашык алсаң да кими.

Калсын бу якты дөньяда
Кешеләрнең гүзәллеге.
Яратам шул чәчәкләрне —
Берсен генә өзәм инде.

## ЯЗ НУРЛАРЫ УЙНАГАНДА

Уйнаганда яз нурлары
Гөрли күгәрченнәрем.
Күгәрчен итеп үземне
Килә күрәселәрем.

Әллә нигә су чәчрәтеп,
Биисем килде әле.
Гөрләп тә җибәрәм инде,
Күңелемнең җилле мәле.

Мин дә язның бер баласы,
Дөньяга килдем көлеп.
Күгәрчен булып гөрлим дә,
Сайрыйм сандугач кебек.

## СӨЕП УЯТАЛАР АНАЛАР

Җирне, гүя, берүк туңмасын, дип
Мамык юрганнарга төрә ул.
Тыныч йоклыйсыңмы, дигән кебек
Кабат, кабат аңа иелә ул.

Ә бит аның балалары күпме:
Венерасы, Марсы, Нептуны!
Барсына да шифа, назы җитә,
Сокландыра аның ныклыгы.

Җылы язлар килгәч, әйтә сыман:
— Уян, балам, йокың туйгандыр.
Йомшак, көмеш бармаклары белән
Ипләп кенә тарта юрганын.

Безне дә бит назлап йоклаталар,
Сөеп уяталар аналар.
Аналарда Кояш гомере булсын,
Җирнең матурлыгы — балада.

## ЮЛГА ЧЫКСАМ

Юлга чыксам, сагышланып,
Моңаеп каласыңдыр,
Уйларың белән артымнан
Ияреп барасыңдыр.

Кулларыңны болгый-болгый
Калма син, әнкәй, елап,
Әйләнеп кайтырмын сиңа,
Булса да юлым ерак.

Киткәндә озата чыксаң,
Җиңел була юлларым.
Яктырта барыр юлымны
Күңелеңнең нурлары.

## НИГӘ, ӘТКӘЙ, МОҢЛАНДЫҢ

Иртәнге талгын, саф һава,
Ат лырт-лырт юртып бара.
Якынлашып килә урман,
Үткәнбез шактый ара.

Әтием тик болай гына:
— Әйдә, малкай! — дип куя.
Каккалый ак дилбегәсен,
Янәсе, атны куа.

— Өшемәдеңме, улым? — дип
Сораштырып алгалый.
— Тирә-ягыңны карап бар,
Күзең йомып калма, — ди.

Җылыта каплап битемне
Җылы куллары белән.
Туңсам әгәр, күлмәген дә
Салып бирәсен беләм.

Чана астыннан сузылып,
Ялтырый ике тасма.
Авылым күздән югалды,
Төшәбез үрдән аска.

— На, малкай! — дип кабатлады,
Тарткалап дилбегәсен.
Күңелен ник нечкәргәнен
Килә минем беләсем.

Җырлап җибәрде әтием,
Юлда күңел үсәдер:
— Һаваларда йолдыз, ай, ничәдер,
Санаган саен күчәдер...

Нигә, әткәй, карлы юлда
Таң атканда җырладың?
Җырыңның соңгы сүзләрен
Ишеттерми, тын калдың?

...Таңнарда йөрим урманда,
Ишетеп тавышыңны.
Әллә шуңа бәйләдемме
Моңга үз язмышымны?

## ӘНКӘЙ ПЕШЕРГӘН ИКМӘК

Атланмай якты әнием
Кара икмәк телеменә.
Бал да яккач, икмәк белән
Йота яздым телемне дә.

Еллар үтте. Өстәлемдә
Май бар, икмәк телеме дә.
Әнкәй пешергән икмәкнең
Тәмен эзли телем генә.

## НИК КИТТЕҢ?

Йөзең якты, күзең нурлы иде,
Йөгереп чыга идең каршыга.
Килгән саен табын әзерләдең,
Уңган идең эшкә, аш-суга.

Ул сөйләшкән сүзләр бетмәс иде,
Сизми идек вакыт үткәнен.
Без яратып сезгә килә идек,
Син сагынып безне көткәнсең.

Шау-гөр килеп матур яшәгәндә
Кара кайгыларга уралдык.
Һушларыбыз китеп бу хәсрәттән,
Чак аякта басып торалдык.

Гомерең аръягына китеп бардың,
Авыру да түгел идең бит.
Яшәргә дә яшәргә иде дә,
Көтмәгәндә үлеп киттең ник?

Оҗмах ишекләрен киң ачсын, дип
Кырыгына килдек җыелып.
Изге җанлы гүзәл әнкәбезнең
Кабере торсын нурда коенып.

## САГЫНАМ СИНЕ, ӘНКӘЙ

Рәсемеңә озак карап торам,
Актарганда альбом битләрен.
Ишетәсеңме, әнкәй, сызлап-сагынып,
Йөрәгемнең ярсып типкәнен?

Белмим, нигә озын керфекләрем
Кайнар яшьләремә манчыла?
Альбом битләренә тып-тып тама
Күзләремнән аккан тамчылар.

Күкрәгемә сыймый, сагышланып,
Дулкыннардай дулый хисләрем.
Нигә безне кинәт ятим иттең,
Нишләдең син, әнкәй, нишләдең?

Яшәдең син тормыш кадерен белеп,
Яңа көн туганга куанып.
Сары сагышларны басар өчен
Рәсемең дә ярап куя бит.

Язлар саен шаулап чәчәк ата
Син үстергән иркә гөлләрең.
Татлы төшләр генә булган икән
Бергә дөнья көткән көннәрем.

## БЕРГӘ ҮТТЕ ГОМЕР ЮЛЛАРЫБЫЗ

Бергә үтте гомер юлларыбыз,
Матур кошлар кебек сайрашып,
Авыр тормыш йөген тарта-тарта
Дөнья казанында кайнашып.

Кайгы-хәсрәтләргә бирешмәдек,
Каршы бардык хәтәр җилләргә.
Көрешкәндә сүзләр бетми иде,
Йокмый иде телләр телләргә.

Күпме күрдем синең шәфкатеңне,
Рәхмәт яусын изгелегеңә.
Гашыйк идем синең һәр эшеңә,
Кулларыңның җитезлегенә.

Яшәдең син җиргә гашыйк булып,
Кылган эшләреңнән тәм табып.
Мәңге шулай дуслар булып яшик,
Урман, чишмәләрдән ямь алып.

## ГОМЕР ЮЛДАШЫМ РӘШИДӘГӘ

Күңелемнең сахрасында
Бердәнбер чәчәгем син.
Син булганда дөньям матур,
Хәтта оҗмахларга тиң.

Кайчагында баш өстемдә
Куерса кара болыт,

Таратасың аларны син,
Игелекле җил булып.

Чыксам юлга, хәстәрлекләп
Мине озатучым син.
Кайгы килсә, җан әрнесә,
Мине юатучым син.

Изгеләр затыннанмы син,
Әүлияме әллә син?
Әйтмәсәм дә беләсең ич
Уйларымның һәммәсен.

Көнләшеп тә куям кайчак
Акыллы булганыңа.
Балаларның өзгәләнеп,
«Әнкәй!» дип торганына.

Уңганнар гына туадыр
Яңа ел иртәсендә.
Йөрәгем типкән чагында
Табынам, иркәм, сиңа.

## СИҢА

Сиңа телимен көннәрнең
Иң җылысын.
Бәхетләрнең, шатлыкларның
Туп-тулысын.

Сәламәтлек, сихәтлекнең
Тик көчлесен.
Күршеләрнең ягымлысын,
Гөл төслесен.

Балаларның, оныкларның
Акыллысын.
Якты йөзләре кояштай
Ялкынлысын.

Бирсен гомерләрнең матур
Һәм озынын.
Татлы төшләр, уйлар белән
Таң сызылсын.

## РЕЗЕДАГА

Чәчләреңне иркәләсен
Сигезенче март җиле.
Бәйрәм белән кайнар котлыйм,
Бәрдәнбер кызым, сине.

Бәхетле бул, рәхәт яшә,
Гаиләң тату булсын.
Яз чәчәкләре шикелле
Йөзләрең матур булсын.

## УЛЫМА

Телеңә ягылган булсын бал да май,
Сөйлә сүзең ялганламый, алдамый.
Көчле булсаң да, курык син хәрамнан,
Тиен өчен калтыранган саран нан.

Ир-егеткә җитмеш төрле һөнәр аз,
Эшең унса, күңелеңдә балкыр яз.
Уйлап эшләнгән эшнең мул җимеше,
Балаларыңа да чыгар өлеше.

Бәхәсләшмә, йөрмә сүз көрәштереп,
Кешеләрне ярсытып, көнләштереп.
Сатлык җаннар алдырырлар эшеңнән,
Аерырлар туганың, дус-ишеңнән.

Кешеләрнең байлыгына кызыкма,
Күпләр эшләп үз тормышын ныгыта.
Ата-анаңа турылыклы хезмәт ит,
Хәзинәңдә бары белән хөрмәт ит.

Азып-тузып йөрмә кеше көлдереп,
Кеше икәнлегең уйла иң элек.
Изгелегең кайтыр әйләнеп кире,
Кадерләсәң игелекле туган Җирне.

Мохтаҗларны ярдәмеңнән ташлама,
Шунда хөрмәт, шунда иман башлана.
Шулчагында әйтерсең, мин шат, диеп,
Бөтен тормышым, гомерем пакь, диеп.

## ЛИЛИЯМ

Кил әле, кил, Лилиям,
Синдә аклык, синдә ямь.
Күтеп алган аккошым,
Кояш кебек балкыйсың.

Син минем куанычым,
Шатлыгым, юанычым.
Йөрәк итем, күз нурым,
Мәңге онытылмас җырым.

Биепләр киткән була да,
Чәбәкәй иткән була.
Уенчыкларын күрсәтеп,
«Мә, уйна» — дигән була.

Кил әле, кил, Лилиям,
Иркәләп, назлап сөям.
Күтәреп биим әле,
Күкләргә чөйим әле.

Ике битең пар алма,
Күзләреңнән нур тама.
Бәхетең белән үс, кызым,
Гомерең булсын озын.

## ӨЙ ТОРА КӨЛЕП КЕНӘ

Сөбханалла, мәчет кебек
Яңа өй җиткергәнсез,
Бу кадәр агач-ташларны
Ничекләр китергәнсез!

Кем соң сезнең «башковитый» —
Әллә инде Фәнитме?
Әллә туганнар җыелып,
Бу зур эшне хәл итте?

Анык кына әйтә алмыйм,
Ничек булса да булган.
Энекәшләр нәкъ Казанда
Күркәм өй коеп куйган.

Үзенә өй салучылар
Шәһәрдә сирәк була.
Тернәкле, оста егетләр
Авылда ешрак туа.

Бу өлкәдә мин үземне
Мактый алмыйм, кәнишне:
Мастерок тотсам, келт сына,
Балтага кул ябышмый.

Тотындыммы берәр эшкә,
Үз башым белән уйлап,
Һич очына чыга алмый
Йөрим җанымны кыйнап.

Энекәшләр алай түгел,
Энекәшләр булдыра.
Шуңа күрә, мин масаеп,
Өй туенда утырам.

Хуҗалар мөлаем булгач,
Тора өй көлеп кенә.
Яшәгез бер-берегезне
Кадерләп, сөеп кенә.

## ОЛЫ БӘЙРӘМ, КЕЧЕ ТУЙ

Әйтсәләр әйтерләр инде:
«Юләрләнгән бу, — диеп. —
Буранда, карлы урамда
Көнен үткәрә биеп».

Канатлар үскәндәй була
Күңелем нечкәргәндә.
Сөенгәндә бүтәннәр дә
Белмидер нишләргә дә.

Олы бәйрәм, кече туйда
Биисем килеп тора —
Роддом тәрәзәсе аша
Оныгым авыз ера.

## ОНЫГЫМ ИЛМИРӘГӘ

Илмирәгә уналты,
Ә миңа алтмыш алты.
Икебезнең дә күңел шат,
Йөзебез нурлы, якты.

Күп тә түгел, әз дә түгел,
Аерма илле яшь кенә.
«Оныкларым бар!» — дип сөенеп,
Күзләремә яшь килә.

Ай, кояш көлеп карый,
Бәхетле тормыш кайный.
Чәчәген суза гөлләр:
«Рәхим итеп ал!» — диләр.

Чүкеч, кадак та сиңа
Каршылыксыз буйсына.
Ходай мәхрүм итмәгән
Чибәрлектән, буй-сыннан.

Үстең минем күз алдымда
Акыллы, тыйнак булып.
Үстең син уйнап, көлеп,
Үсмәдең елак булып.

Изге теләкләр телим
Сиңа туган көнеңдә.
Кояшлы булсын һәр көнең,
Сәламәт бул гомергә.

*21 август, 2000*
*Истәк*

## ИСЕМ ТУЕ

Ерак юлны якын итеп
Килдек сине күрергә.
Җисемеңә тиң килерлек
Матур исем бирергә.

Башларыбыз күккә тиде,
Асыл ир бала тугач.
Борыны — әтисенеке,
Кашлары — кара, кыйгач.

Әткәң, әнкәң — пар канатың.
Үс имәндәй нык булып.
Рәхмәт, улым, сөендерден
Якты дөньяга туып.

Мулла бабаң кушкан исем —
Азат синең исемең.
Исеме шулай матур була
Илен сөйгән кешенең.

Көл әле, көл, кояш кебек,
Аша да йокла, ял ит.
Кояшны көнләштерерлек
Сәламәтлегең бар бит.

Кабул иттең исемеңне
Яратып, көлеп кенә.
Нәсел-нәсәбеңне, улым,
Онытма берүк кенә.

## КОТЛЫ БУЛСЫН

Балконыгыз каршысында
Шомыртлар чәчәк ата.
Шомыртлар чәчкәсен суза
Сезнең дүртенче катка.

Сандугачлар сузып сайрый
Сезгә шат гомер теләп.
Туган-тума бергә булгач,
Өй эче тора гөрләп.

Өй туйлары күркәм булсын,
Истә калсын гомергә.
Ак бәхетләр юлдаш булсын,
Кайгы күрмәгез бер дә.

Фатир өчен көрәштәге
Җиңеп чыккан көнегез.
Тиң мәхәббәт чәчәк атсын,
Котлы булсын өегез!

## ГҮЗӘЛГӘ

Безгә сине бер күрүе
Күңелле бәйрәм кебек.
Кырык эшебезне ташлап,
Туган көнеңә килдек.

Күз алдыбызда үсәсең,
Көннән-көн чибәрләнеп.

Килдек сине биетергә,
Арканнан сөяргә дип.

Бүген туган көн икәнен
Кояш беләдер әле.
Сине котлап, тәрәзәңнән
Нурлар сибәдер әле.

Сиңа телибез дөньяның
Бар ямен, бар аклыгын.
Сау-сәламәт, гомерле бул,
Артсын бәхетең, шатлыгың.

Яңавылыбыз бик якын
Без яшәгән авылга.
Сиңа атап җырлар язам
Бик сагынган чагымда.

*22 сентябрь, 2000*
*Истәк*

## ОНЫКЛАРЫМ КИЛГӘНДӘ

Гүзәл, Илмирә, Эльбрус –
Сокланырлык якын дус,
Дус кына түгел, туган,
Өчесе дә бик уңган.

Һәрберсендә якты йөз,
Җан эретер татлы сүз.
Белмәгән эшләре юк,
Өчесе дә эштә ут.

Кушканны һич көтмиләр,
Эшне белеп эшлиләр.
Бүленгән һәркемгә эш —
Кем ни эшләргә тиеш.

Савыт-саба юылган,
Матур тезеп куелган.
Өстәл өсте сөртелгән,
Гөлләргә су бөркелгән.

Әй уенга килгәндә,
Уздыралар миннән дә.
Ул кычкырыш, ул көлеш,
Дөбер-шатыр йөгереш.

Иң кечкенәбез, хи-хи,
Диванда җырлый-бии.
Өлкәне стенканың
Өстендә, җаным, йөри.

Уртанчыбыз кайда соң?
Берүк читтә калмасын.
Шифоньерны ачкан ич,
Шунда кереп качкан ич.

Сайратабыз гармунны,
Яратабыз җыр-моңны.
Кассетабыз да әзер,
Күмәк биибез хәзер.

Биибез дөбер-дөбер,
Күңелле үтә гомер.
Белә ут күрше-күлән:
Оныклар куна килгән.

## УРТАК БӘЙРӘМ

Өй туйлары — уртак бәйрәм,
Туган-тума җыела.
Сый-хөрмәттән хуҗаларның
Өстәлләре сыгыла.

Кабарып пешкән икмәкнең
Баллы-майлы өсләре.
Өйгә сыймый, тышка чыккан
Аш-суның хуш исләре.

Күзләрне назлап, иркәләп
Бүлмәләр балкып тора.
Аллы-гөлле тәрәзәләр
Кояшны тартып тора.

Көтеп алган бәйрәмебез,
Шатланыйк бергә-бергә.
Түбәләр күккә тигәндә,
Аяклар тими җиргә.

Илмирә белән Эльбрус
Уйнасын шау-гөр килеп.
Кияү эштән кайткан саен
Ишекне ачсын көлеп.

Кызым Резеда йөзендә
Уйнасын якты нурлар.
Тик бәхет, шатлык китерсен
Үзегез корган юллар.

Җыелдык авыл-каладан
Туган-тума, дус-ишләр.
Исләремнән чыкмас инде
Өй котлаган бу кичләр.

## ГАЗИМӘ АПАМА

Таңнарда торып кояшкай
Нурларын сипте сиңа.
Шатланып, балкып киләсең
Җимешле җитмешеңә.

Сокланмаска мөмкин түгел
Эшләгән эшләреңә.
Куанып, сөенеп яшә
Үзеңнең көчләреңә.

Агачыннан ерак төшми
Алмагачның алмасы.
Син — мәгърифәткә юл ачкан
Дүрт мөгаллим анасы.

## НӘГЫЙМӘ АПА

Нәгыйма апа, күңелең саф,
Инсафлы, игелекле.
Авылдашларың алдында
Эшләрең изгелекле.

Әйткән сүзең — китап сүзе,
Син шигырьләр остасы.
Фәрештәдәй изге җан син —
Озын сүзнең кыскасы.

## ИМӘН

*Профессор*
*Фираз Фахраз улы Харисовка — 50 яшь*

Үскәннәр имән белән тал
Иркәләнеп иркендә.
Имән Талсыз, Тал Имәнсез
Яши алмый беркөн дә.

Көннән-көн яшәрә имән
Зифа талкае булгач.
Акылы, фигыле белән
Дәрт, куәт өстәп торгач.

Имәнем бар, дип, янымда,
Талкай сөенә икән.
Берсен берсе сөйгән ярлар
Нурга күмелә икән.

Фираз энем Имән булса,
Чулпан бөдрә Тал кебек.
Парлап тапкан бәхетегез
Күккә ашкан тау кебек.

Фәндә тоткан урының бар,
Янында бар сердәшең.
Ат елында, аттай эшләп,
Бәйрәмеңә киләсең.

Илле яшьлек юбилеең
Айлы, кояшлы булсын.
Батырга да ял кирәк, ди,
Шуны онытмыйк, дустым!

*Май, 2002*

* * *

*Үзешчән композитор Вәсил Хәбисламовка*

Сандугачлар туктап тыңлый
Вәсил гармун уйнаса.
Дөнья китек булыр иде,
Син гармунчы булмасаң.

Гармун теле — йөрәк сере,
Былбыл, тургайлар теле.
Асыл затларга бай бит ул
Ягымлы Борай иле.

Көйләрең — гомер юлдашың,
Халкың — алтын терәгең.
Яңа җырлар сорап тора
Тынгы белмәс йөрәгең.

## ВӘНЗИР ГАЛИНГА

Вәнзир дус чыгып бастымы,
Нурлар балкый сәхнәдә.
Үземне хис итәм шунда
Тургайлы киң сахрада.
Эчендә әллә кош бармы,
Гармуны сайрап тора.
Беләм, йөрәк түрләрендә
Дәрт ташып, кайнап тора.
Тормышта ямь буламыни,
Гармуннар уйнамаса.
Күңеләңне тетрәндереп,
Сагыш-моң уянмаса.

## ИЗГЕ ҖАНЛЫ ӘЛФИЯ

Аккошка охшатам сине,
Ак халатыңны кисәң.
Сүнгән өметләр терелә,
Палатама син керсәң.

Ягымлы йөзең елмая,
Кояшны көнләштереп.

Күңелемне күтәрәсең,
Акыллы киңәш биреп.

Табибларның ихласлыгын
Аңлый тик авыру гына.
Йөрәк җылыңны кушмасаң,
Терелтми дару гына.

Фәрештәдәй изге җан ул —
Безнең табиб Әлфия.
Авырулар сихәтлек алып,
Бәхет теләп баш ия.

## АВЫЛ БАЛАСЫ

*Мөниргә*

Аякта киез итек —
Куркытмый кышкы суык.
Чалбарым җылы минем,
Дәү әни бирде сырып.

Өстемдә тун, башымда
Өр-яңа куян бүрек.
Телен шартлата суык,
Урамда мине күреп.

Битемне чеметтереп,
Хәтта ала көйдереп.
Ул куган була шулай:
— Өеңә кайт, йөгер! — дип. —

Юкса сине туңдырам,
Чыгарып салкын буран.
Бер җан иясе дә юк,
Әнә бит буп-буш урам.

— Ак сакаллы Кыш бабай,
Туңдырам, дип куркытма.
Уйнасам, тик тормасам,
Салкының да җылыта.

## «ӨМЕТ»КӘ

Кар кебек кәгазь өстендә
Өметле эзләр ята,
Шул эзләрдән атлап барсам,
Яшьлегем кире кайта.

Һәр эздә тормыш аһәңе,
Кайнарлыгы хисләрнең.
Күрәм кимчелекне куып,
Садә җилләр искәнен.

Ышанам: шул кайнар эзләр
Чыгарыр олы юлга.
Батырмас саз-сазламыкка,
Җибәрмәс уңга-сулга.

Яңалыкка, изгелеккә
Шул юллар ирештерер.

Күңел күзләрен ачар да,
Дус белән күрештерер.

Яшьлектә кемгә дә авыр
Үз юлларын табуы.
Каләмнәрнең үткенлеге
Яман шешкә дару ул.

Рәхмәт изге эш башлаган
Игелекле яшьләргә.
«Өмет» безгә куәт бирсен,
Илһам бирсен яшәргә.

## АХИРӘТЕМ «КЫЗЫЛ ТАҢ»

*80 еллыгына*

Башка телне өстен күреп,
Үз телеңне «онытсаң»,
Яман хатаңны аңлатып,
Киңәш бирер «Кызыл таң».

Кара болыт басса күңелең,
Ялгыз калып боексаң,
Айлы, кояшлы булырсың,
Килеп торса «Кызыл таң».

Яшьләргә дә, картларга да
«Кызыл таң»да җимнәр бар.
Имансызларны иманга
Кайтарырлык имнәр бар.

Исерткечкә әвәсләнеп,
Рюмкаларга сузылсаң,
Аңла: аракы — дошманың,
Ахирәтең — «Кызыл таң».

Милләтем язмышы белән
Танышып барыйм, дисәң,
«Кызыл таң»ны алмый калма,
Такыр булса да кесәң.

Татлы йокыдан уятып,
Сызылып ата кызыл таң.
Данлы юбилееӊ белән,
Ахирәтем «Кызыл таң».

## МӘКТӘБЕМӘ

Сагынып кайттым туган мәктәбемне,
Дулкынланып ачам ишеген:
— Исәнмесез, укытучыларым,
Саумы, мәктәп, алтын бишегем.

Килгән саен көлеп каршылыйсың,
Аккошлардай җәеп канатың.
Аркалардан сөеп, якын күреп,
Әнкәйләрдәй безне яраттың.

Онытылмый дәресләргә дәшеп,
Көмеш кыңгыраулар чыңлавы.
Уңган остазларым, рәхмәт сезгә,
Күңелле иде сезне тыңлавы.

Иң бәхетле көннәребез булган
Синдә укып үткән гомерләр.
Гаделлеккә өйрәндек без синдә,
Шуңа якты безнең күңелләр.

## УКЫТУЧЫМА

*Барый Самат улы Салиховка*

Вакыт, вакыт, зинһар, тыңла мине,
Алып кайтчы сабый чакларга.
Тик бер көнгә, бер сәгатькә генә
Пар канатлы акбүз атларда.

Мәктәпләрдә үткән шат көннәрен
Сагынмаган кеше булырмы?
Языйм әле сыйныф тактасына,
Акбурларга буяп кулымны.

Гомерем буе газиз укытучым
Атлый минем белән янәшә.
Нинди бәхет, укучысы әгәр
Эше белән илен ямьләсә.

Балкый дөньям, әллә күзләрендә
Янгангамы өмет нурлары.
Җуеп булса икән, серен белеп,
Маңгайларга яткан сырларны.

Кире кайтмаса да, сабый чаклар
Хәтер канатында тирбәлә.
Укытучым, мәгърур хезмәтеңне
Тик кояшка мөмкин тиңләргә.

## КИЛӘЧӘККӘ КАРЫЙМ ӨМЕТ БЕЛӘН

Мәктәбемдә күкрәп, яшьнәп үткән
Алтын гомеремне кызганмыйм.
Бәхет орлыклары чәчә-чәчә
Сизмәдем дә еллар узганын.

Рәхмәт яусын укучыларыма,
Артта калмадылар тормыштан.
Уңган ата-ананың балалары
Тырыш була бит ул тумыштан.

Киләчәккә карыйм өмет белән,
Яшьле күзләремне талдырып.
Акыллы һәм көчле шәкертләрем,
Һәрберегездән үрнәк алырлык.

## ИСӘ ЯҢАРЫШ ҖИЛЛӘРЕ

Халкымның яшәешенә
Кул селтәделәр тәмам.
Тик үз кайгылары кайгы,
Акча сосалар һаман.

Ришвәтчегә, ялагайга
Табалар җылы урын.
Эче чиста булмаса да,
Югары менде борын.

Акладылар каракларны,
Үтерүчене хәтта.
Намуссызлар данга менде,
Нинди аяныч, хата.

Әрәмтамак, җилкуарның
Киселмәде ризыгы.
Комсызлар кулына күчте
Дөньяның бар кызыгы.

Үзләре туйган байлыктан,
Тик туймаган күзләре.
...Исә яңарыш җилләре,
Бәлки тормыш үзгәрер?

## КӨТКӘНДӘ

Чал Урал, Агыйдел көтә,
Көтә Уфа, Яңавыл.
Егерме беренче гасыр,
Сине көтә Яңа ел.

Сине көтә, өмет итә
Алга талпынган күңел.
Булмасын бәла-казалар,
Дөньялар булсын имин.

Яңа Ел килер алдыннан
Кояшым карый көлеп;
Яңа гасырда яшәрбез
Шатланып, дигән кебек.

*Декабрь, 2000*

## ЯҢА ЕЛ СӘГАТЕ СУГА

Утырышыйк җайлап кына,
Өстәлебез түгәрәк.
Алдан килгән — урын өчен,
Узыгыз, уз түргәрәк.

Яңа Ел күчтәнәчләре
Кунаклаган табынга.
Яшел чыршы — бәйрәм күрке,
Бер сүнә, бер кабына.

Пилмәннәр пешеп өлгерде
Майлы шулпада йөзеп.
Кыш бабай да килеп җитәр
Җирне, күкләрне гизеп.

Бәйрәм бәйрәм төсле булсын,
Җырлап утырыйк әле.
Бокалларга күпереп торган
Ширбәт тутырыйк әле.

Җырламаган җыр калмасын,
Биик без бөтерелеп.

Ашыйк-эчик, уйныйк, көлик,
Булмасын үкенерлек.

Төкле аягың белән кил,
Көтеп алган Яңа Ел.
Гирлянда түгел, теләкләр
Шулай балкып яна ул.

Ишәйсен яшь гаиләләр,
Уңган балалар тусын.
Яңа Ел уңышы белән
Илебез көчле булсын.

Иминлек, муллык алып кил
Һәр авылга, шәһәргә.
Матур, сәламәт тормышта
Насыйп булсын яшәргә.

Яңа Ел сәгате суга,
Чыңлатыйк бокалларны.
Изге теләк теләп бергә
Каршылыйк ал таңнарны.

## ДӨНЬЯ МАТУР

Дөнья иркен хөр күңелле кешеләргә,
Берсен-берсе хөрмәт иткән күршеләргә.
Кулларында кош уйнаткан ир-атларга,
Иман нурын өстәп торучы затларга.

Дөнья якты берсен-берсе аңлаганга,
Кояш күрсә генә алма алмалана.

Кара болыт кабармас, дип ышанма син,
Азындырма, тый нәфсеңне, тышаула син.

Дөнья матур сөенгәнгә, сөелгәнгә,
Күкрәгеннән гыйшык уты түгелгәнгә.
Саф йөрәген бүлгәләми яшәгәнгә,
Тиң мәхәббәт бакчасында яшьнәгәнгә.

## КҮТӘРЕЛӘ КОШЛАР КҮКЛӘРГӘ

Күкрәкләрен җилгә каршы куеп,
Күтәрелә кошлар күкләргә.
Кычкыралар: «Бергә очыйк!» — диеп,
Баш өстемнән шаулап үткәндә.

Берчә уйнап, берчә канат кагып,
Кошлар оча зәңгәр киңлектә.
Бергәләшеп тату яшәүләре
Кошларга да нинди килешә.

Сезнекедәй гәүдәм җыйнак булса,
Авырлыгым шактый кимесә,
Кошлар көтүендә бер асыл кош
Булыр идем мин дә югыйсә.

Белмим, нигә Ходай бәндәләрен
Мәхрүм иткән көчле канаттан?
Очар өчен түгел, кешеләрне
Җирне ямьләр өчен яраткан.

## БӘХЕТ ОРЛЫКЛАРЫ ЧӘЧЕП

Тау кадәрле кайгыларым
Сыртын кабартып тора.
Маен имеп, йөрәгемне
Тырнап, канатып тора.

Кайгы кара гына булмый,
Канлысы да җитәрлек.
Салкын чишмә суын эчәм,
Юып алып китәр дип.

Кайда соң сез, шатлыкларым,
Ник җиңелеп калдыгыз?
Атылган йолдыз шикелле
Кинәт кенә яндыгыз.

Бәхет ерак йолдыз кебек
Күренә томан аша.
Болай да якын түгел бит,
Ник һаман ераклаша?

Мин ышанам: бер кабынып,
Яктыртырсыз җанымны.
Күтәренке күңел белән
Көтәрмен һәр таңымны.

Шулчагында кайгым тавын
Тигезләрмен җир белән.
Бәхет орлыклары чәчеп,
Тутырырмын гөл белән.

Дөньяның имин булуын
Җанымнан артык күрәм.
Кайгыларны җиңеп була
Акыл, сабырлык белән.

## «МИН – МАТУР»

Матурлык та, батырлык та
Яши икән янәшә.
Икесе бергә кушылып
Бәхет нурлары чәчә.

Рәхәтләнеп шул нурларда
Коенып калыйм әле.
«Мин – матур», – дип,
«Мин – батыр», – дип
Үземне алдыйм әле.

Алданасым килә минем
Хуҗа Насретдин кебек.
Берничә минут булса да
Йөрим күкрәгем киреп.

## УЙЛАР ДИҢГЕЗЕНДӘ

Йөзәм уйлар диңгезендә,
Төбе дә юк, яры да.
Аңлар хәл юк бу дөньяны,
Башым чатнап ярыла.

Уйлар диңгезем болганчык,
Нурлар үтәрлек түгел.
Шаулый диңгез, ярсый диңгез,
Нәкъ минем шашкан күңел.

Тынар әле уй диңгезем,
Шомланыр, болганыр да.
Дөнья кайтыр үз ярына,
Әйләнер, тулганыр да.

## КЕШЕ БУЛЫП КАЛАМ

Никадәрле язмыш каһәрләсен,
Йөрәк итен талап кимерсен,
Якты өметләрне вата-кыра
Кул-аякка богау кидерсен,

Мин барыбер кеше булып калам,
Иманымны сатмый яшәдем.
Табигатьнең горур баласы мин:
Яшен булып балкып яшьнәрмен.

## АРГАМАКЛАР

Аргамакларны этиләр
Иярләделәр.
Ялынсак та, ялварсак та
Ияртмәделәр.

Әйттеләр: «Без кайтырбыз, — дип —
Дошманны җиңеп.
Сабантуйларда йөрербез
Тулпарда җилеп.

Син энием таянычы,
Тыңла, борчыма.»
Әниләр сөртте күзләрен
Яулык очына.

Аргамаклар тып-тып баса,
Юлларда — тузан.
Сагынып ничә ел инде
Шул юлдан узам.

Күреп сөйләшәсе иде,
Әллә соңладык.
Берчә көтәм сагышланып,
Берчә моңланып.

Ил өчен гомерен бирган
Ата уллары
Әтиләрен көтә һаман
Карап юлларны.

Килсә килә генә белә,
Китми ул кайгы.
Күңелебездә әтиләр
Мәңге яшь калды.

## ҖИҢҮ КӨНЕ

Май аеның талгын җиле иссе,
Күтәрелде күккә тургайлар.
Чылтыр-чылтыр чишмә җырын сузды,
Әйтерсең лә сугыш булмаган.

Нинди матур, нинди рәхәт дөнья!
Һавалар саф, балдай шифалы.
Газапларны оныйк, туганнарым,
Ишетегез: сугыш туктады.

Ачык зәңгәр күккә ракеталар
Аллы-гөлле йолдыз сипteләр.
Фронтовиклар Туган ил туфрагын
Учларына алып үптеләр.

## СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ НӘКЫЙП АБЫЕМА

Алтын, көмешкә, шөһрәткә
Яшәдең табынмыйча.
Матур тормыш юлы үттең
Сөрлекми, абынмыйча.

Күкрәгең тулы медальләр —
Гомерең көзгесе ул.
Батырлык — ир-егетлекнең
Җуелмас билгесе ул.

Син шәфкатьле, көчле рухлы,
Ихлас синең ярдәмең.
Күңелеңә туплагансың
Ак дөньяның бар ямен.

## һӘЙКӘЛ КУЙЫЙК

Вакыт, вакыт,
Нигә кабаланып,
Сабый чакларымнан аердың?
Хыял диңгезләрен киптердең дә,
Тамчыларын гына калдырдың.

Озаттылар яуга әтиләрен,
Абыйлары аннан киттеләр.
Атлар урынына нәни куллар
Үгез-сыерларны җиктеләр.

Ир-ат күтәрмәгән авыр йөкне
Балаларның иңе күтәрде.
Уйнап күңел ачасы урында
Гомерләрен эштә үткәрде.

Нәни куллар эшләгән эшләрне
Мөмкин түгел санап чыгарга.
Ачлык, ялангачлык, ятимлекләр
Патша булды утлы елларда.

Сабыйларның сугыш елындагы
Эшләренә хәйран калырлык.
Батырлыкларына тарих язып,
Мәрмәрләрдән һәйкәл салырлык.

## ЯУГИР ЕГЕТ

Сагышланып гитарасын
Алды да кулларына,
Кадерләп, иркәләп кенә
Чиртте дә кылларына,

Сузып-сузып, уйга чумып,
Җырлады яугир егет.
Ерактагы яшьлек дусты
Ишетсен дигән кебек.

...Коля дусты бүләк итеп
Калдырган гитарасын.
Әфганстан сугышында
Башын салган ул лачын.

## СОЛДАТ УЛЫМ, ИЛНУРЫМ

Үтерделәр! Ташлап киттеләр.
Газиз башын таптап үттеләр!
Кан эчендә ята Илнурым,
Төпчек улым минем, күз нурым.
Нәрсә булды, бәгърем, әйтсәнә,
Уф, егылам, башым әйләнә.
Күз йомыла, йөрәк кысыла,
Үләрмендер мин дә шушында.
Кичә ялга кайткан солдатым,
Ышанычым минем, канатым.

Чү, түз, йөрәк, туктап калма син,
Вакыты ул түгел, аңла син.
Син туктасаң, кем соң үч алыр,
Үтерүчеләр җавапсыз калыр.
Түз, йөрәгем, авыр булса да,
Күзләремә кан-яшь тулса да.
Туктатыгыз! Каны акмасын,
Күтәрегез, җирдә ятмасын!
Салкын тиюе бар улыма,
Кулы, аяклары суына.
Күрсәтегез ашыгыч ярдәмне,
Сез кемнәр соң: бүре, адәмме?
Шаулап ага кайнар, эссе кан,
Кемдер, гүя, утта кайнаткан.
Туң җир эри, эри кар, бозлар.
Хәрәкәтсез егет һәм кызлар.
Нишләсен соң, алар ут йоткан,
Әйтерсең лә, барсын ток суккан.
Томаланган яшьле күзләре,
Калтырана гәүдә, тезләре.
Күргәне бармыни яшьләрнең
Мондый вәхшәт, мондый мәхшәрне.
Елый үксеп, әрнеп бар халык,
Күкрәгенә ятып, баш салып.
Кара кайгы басты авылны,
Матур иде Илнур, акыллы.

Күк капусы балкып ачылганда
Ак теләкләр генә теләдем.
Сау-сәламәт, бәхетле бул, дидем,
Гомерең озын булсын, димәдем.

Нигә озын гомер теләмәдем?
Нәрсә бүлде икән уемны?
Шау-гөр килеп сөенеп яшәгәндә
Мин югалттым газиз улымны.
Кошлар кебек очып, канатланып,
Кайтып кердең балкып урамнан.
Әзмәвердәй егет булгансың бит,
Үзеңә карап, шашып куанам.
Шомырт кара күзләр, кара кашлар,
Дулкынланып торган чәчләрең
Әсир итте мине. Төшендем мин
Мәгънәсенә шунда яшәүнең.
Улым-бәгърем, алтын телләренә
Ник ышандың явыз дошманның?
Электән үк белә идең дә бит
Гарип икәнлеген ул җанның.
Кайда иде синең ахирәтләр,
Нигә сине ташлап киттеләр?
Чәчәк кебек гомерең өзелгәндә
Ник куркышып артка чиктеләр?
Кайсылары, күрмәмешкә салышып,
Яшеренгән аулак урынга.
Шундый дуслар чын дус буламыни,
Кайгыртмагач дусты турында.
Кабинада кыйнап, миңгерәүләтеп,
Как урамга ташлап киткәннәр.
Фараларын басып, кабат килеп,
Машинада таптап үткәннәр.
Их, син, дөнья, — кайгы сандыгы син,
Ник юл куйдың вәхши үлемгә?

Улым сине матурларга килде,
Матурлый ул җирне бүген дә!
Сахраларга чыгып эзлим сине,
Тавышыңны кошлар моңыннан.
Күреп, сөйләшеп тә туя алмадык,
Китеп бардың кайткан юлыңнан.
Кемнәргәдер дөнья тар әле,
Канга сусаганнар бар әле.
Маташалар исбат итәргә
Чынлап ак дип кара карганы.
...Дошман кулы өзде яшь гомерен
Яшьнәп, күкрәп яшәр чагында.
Солдат улыбызның, кояш булып,
Рухы кайта һәркөн таңында.

## ЯЛГЫЗ АНА

Тәмам туйдым инде кара төннән,
Йоклый алмый алҗып бетәм мин.
Тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп,
Өзгәләнеп таңны көтәм мин.

Әллә нинди уйлар килә башка —
Ялгыз ана нәрсә уйламас.
Коръәнемне салам баш астыма,
Җеннәр килеп җанны кыйнамас.

Җәйге кыска төн дә озын миңа,
Сөйләп тормыйм инде кышкысын.
Шылт итсә дә куркып куырылам,
Дога укыйм, Ходам хуш кылсын.

Кояшкаем, зинһар төн пәрдәсен
Җибәр ике якка таратып.
Мин бит сиңа озын гомер телим,
Кочаклардай булып, яратып.

Балаларым оныттылар мине,
Хәлләремне тик син беләсең.
Каһәрләнгән җанны кадерләргә
Ходай сиңа кушкан, күрәсең.

## КАЙДА СОҢ СЕЗ?

Кайда соң сез, кайда, минем улларым?
Җылый-җылый сүрелде күз нурларым.
Ишеттерергә телим хәбәремне,
Беләсегез киләдер хәлләремне.

Әтиегезне салдым җир куенына,
Быел ун ел тулды соңгы туена.
Булгансыздыр башлы-күзле, ир-ата,
Кулларыгыз нинди эшләр кыйрата?

Балаларыгыз берәүме, икәүме?
Алар да үзегез кебек иркәме?
Исемнәре кем: Степан, Иванмы?
Оныттыгызмы милләт, иманны?

Әллә сату итәсезме базарда?
Кәгазь тапмыйсыздыр бер хат язарга.
Адресым шул, исемем генә яңа:
Балалыдан баласыз калган ана!

## ПЕШӘ ТОРА

Пешә тора сүз боткасы,
Үзеңне-үзең мактау.
Эчпошыргыч шапырыну,
Һәм гаепләне аклау.

Нинди генә сүз юк хәзер
Әйләнештә йөрмәгән?
Ул сүзләр тел сындырырлык,
Ишетмәгән, белмәгән.

## ХАСТАХАНӘДӘ

Ятам хастаханәдә ах-вах килеп,
Ятам — терелеремне алдан белеп.
Күкрәгем кысыла, һич җитми һава,
Калтырыйм, дер-дер киләм, тәнем яна.

Йөрәгем сызлана әрнеп, башым ут,
Саташтыра, китсәм кайчак басылып.
Тыныч түгел күңелкәем, әзләнә,
Күпне күргән гомерем көйсезләнә.

Русиябез авыру бүген — борчылам,
Халыкларга бирче гакыл, бир чыдам.
Анда комсызлык, фәхишлек, үтереш,
Яши алырбызмы озак шул килеш?

И сихәтлек бүләк иткән табиблар,
Баш ия сезгә авырулар, гарипләр.

Рәхмәт укыйм: ярлыкыйсыз үлемнән,
Сез — фәрештә, ак халатлы киемнән.

Ярый әле килгәнмен соңламыйча,
Терелттегез, яшимен сызланмыйча.
Мин ышанам: Русия дә савыгыр,
Савыктырыр табиблары табылыр.

## ӘЙТЧЕ

Кайсы илдә яшәгәнне
Оныттык та бугай.
Чит ил кинолары басты,
Җыр-музыка да шулай.

Азык-төлек, кием-салым —
Чит илнеке һәммәсе.
Кайда соң үзебезнеке,
Әйтче, алла бәндәсе!

Ялкау дигән ялган гаеп
Күтәрә бөек халкым.
Эшсезлектән җәфалана
Булса да кулы алтын.

* * *

Дөнья күрсәтеп өлгерде
Алдын да һәм артын да.
Нәрсәдер күрсәтә тагын:
Кара әнә, тартынма...

## КӨЯЛӘНӘМ КЫЗ ЯЗМЫШЫ ӨЧЕН

Ташлап киткән өзелеп сөйгән яры,
Сыны катып үкси сылу кыз.
Шул матурны зинһар юатыгыз,
Ярдәм кулыгызны сузыгыз.

Елый-елый шешенгән күзләре,
Кулъяулыгы манма су булган.
Калтырана, әрни җаны-тәне,
Яшәүләрдән күңеле суынган.

Көяләнеп кыз язмышы өчен,
Тәмуг утларында янамын.
Әйт, син, егет, машинаңда йөртеп,
Сылукайны нигә алдадың?

Бәхет тамырына балта чабып,
Күңел ача этрәк-әләмнәр,
Пычрак җанны агартырга теләп,
Тузсалар да кагәзь-каләмнәр.

Алданганнар тик син генә түгел,
Хакы алтын-көмештер инде.
Күрмәгәннең күрәсе килә дип
Әйтүләре дөрестер инде.

И чибәр кыз, үз-үзең бетермә,
Өметеңне өзмә, ярсыма.
Таңда искән йомшак җилләр сыман
Мәхәббәтең килер каршыңа.

## ИМАНЫ БАР

Халык ашыгып бармаса да,
Һәр авылның мәчете бар.
Дин юлында йөргәннәрнең
Иманы бар, бәхете бар.

Түрәләр йөрми мәчеткә,
Утыралар банкетларда.
Безгә мәчет салыштылар,
Ник аларны тәнкыйтьләргә?

Мөмкинчелегеңнән чыгып,
Алып бар сәдака-хәер.
Күңелең ачылып кайтыр,
Иманың һәм рухың баер.

## БУЛГАНЫ ЯРАП ТОРА

Картлык кире китә белми,
Тик килә генә белә.
Маңгайларны сырлый-сырлый
Баш түбәсенә менә.

Әфсен-төфсен укый-укый
Чәчемне йолка башлый.
Ак чәчләрең куе булса,
Кычыттыра, ди, башны.

Җитмештәгеләр, ди, күптән
Манный боткасы ашый.

Чуртымамыни сиңа теш,
Өзгәләп, йолкып ташлыйм.

Анда-монда сугылып йөрмә,
Җитте сиңа, ваксынма.
Әнә сиңа ишек төбе,
Бөгәрләнеп ят шунда.

Колакларга мамык тыга,
Ишетмә, дип, артыгын.
Башка дөнья пәйда була
Килеп җитсә картлыгың.

Маңгаеңны буразналар
Ергалаган, дисәгез,
Битеңне җыерчык баскан,
Чарасын күр, дисәгез,

Пластик операцияләр
Җыенмыйм ясатырга:
Ясалма гомер кирәкми,
Булганы ярап тора.

## ГАЗРАИЛ

Ашыгып килеп тә җиткән,
Көтмәгән чакырганны.
Әллә алдында, мах биреп,
Сузылып ятаргамы?

Хәлемне белеп чыгыйм, дип
Яныма кергәндер ул.
Юньтерәбрәк торганны
Ишетеп белгәндер ул.
Учына салып йөрәкне,
Кысып, чеметеп карый.
Хәле бетеп туктап тора,
Ахры, куллары арый.
Капшап бавыр, бөерләрне,
Үпкәләргә сугыла.
Нәфсең тәмам азган икән,
Минем яннан шу гына!
Вакытымны әрәм итеп
Йөрмә әле, Газраил.
Бозыклыгым булса әгәр,
Җәлләп торма, җәза бир.
Тавык чүпләсә дә бетмәс
Эшемә аяк чалма.
Мине карт-коры дип түгел,
Ир уртасы дип санла.
Оныкларым буйга җитте,
Килен төшерәсем бар.
Балаларын үчтек итеп,
Назлап үстерәсем бар.
Шәм кебек бүрәнәләрдән
Өйләр күтәрәсем бар.
Төпчегемнең алтын туен
Җырлап үткәрәсем бар.
Яннарыма килүеңнең
Аңламадым сәбәбен.

Оҗмах кошы улыбызга
Җиткер кайнар сәламем.
Кайчак ялгышып китәсең,
Яшь гомерләр өзелә.
Гел-гел канлы яшь түктермә,
Изге эш тап үзенә.

ТЕАТР

*(Уены-чыны бергә)*

Түшәктә ятам авырып, газапланам,
Кемдер, гүя, гәүдәмне кадаклаган.
Саташтыра, шомлы уйлар уйлатып,
Күзләремдә яшен уты уйнатып.

«И ходаем, кызганчы мин бәндәңне,
Чиремне ал, тормышымны ямьләле.»
Әллә тәңрем теләгемне ишеткән,
Хәләлемнең йомшак сүзен ишетәм:

— Соңга калабыз, — ди, — әйдә, тор, юын,
Онытмагансыңдыр ич клуб юлын.
Менә үтүкләнгән күлмәк, галстук.
Ашык, зинһар, башкалардан калышмыйк.

— Ничек барыйм, шыбыр су бөтен тәнем,
Янымда сагалап тора әҗәлем.
— Терелерсең, ахирәтләрең килгән,
Белдерүдә: «Яңавыл халык театры» диелгән.

— Ничек, ничек? Яңавыллар, дисеңме?
Бармы Нәфисә һәм Хәбир* исеме?
Исемнәрендә биоток бар әллә?
Һушым китте: чирем качты шул мәлдә.

Йөрәгемдә шашкан хисләр ургыла,
Коеныймчы күзләренең нурында.
Һәр чыгышлары сәхнәдә — куаныч,
Пакьләндереп, бозыклыкны куа ич.

И сәләтле, илһамлы кардәшләрем,
Хак сүз бит ул: сез — үрнәге яшьләрнең.
Саклаганга киләчәген милләтнең,
Халкым зурлый талантлары хезмәтен.

Бик сөендем: биеп тә җырлап алам,
Театрга шуышып булса да барам.
Театр ул сафландыра күңелне,
Хәтта озайта диләр бит гомерне!

## КҮҢЕЛЕҢНЕ ТОТМА ЧИТЛЕКТӘ

Күңелеңне тотма читлектә,
Үз җаныңны үзең кимсетмә.
Җәфалама аны тышаулап,
Түгел бит ул явыз, усал зат.

---

* Нәфисә һәм Хәбир Харисовлар — Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәрләре, Яңавыл татар халык театры артистлары.

Авызлыклама ул чапканда,
Уйнап йөрсен кырда, яланда.
Менсен гөмбәзенә күкләрнең,
Ишетсен ул күкнең күкрәвен.
Төшсен диңгезләрнең төбенә,
Төптән көндез йолдыз күренә.
Үрмәләсен бәхет тавына.
Сагынып кайтсын туган ягына.
Сандугачлар булып сайрасын,
Ялгыз калса, кипсен, саргайсын.
Оҗмахларга кереп әйләнсен,
Гөнаһы булса, тапсын хәйләсен.
Тәмугында көйсен канаты,
Тәмуг бит ул — яшерен ярату.
Йөрсен халык моңын ишетеп,
Матурлыкны алсын ише итеп.
Дошманнардан дустын аерсын,
Дусларыңнан илһам алырсың.
Тарихларның серен чишсен ул,
Иблисләрнең юлын киссен ул.
Мәхәббәтен тапсын, аңлашсын,
Фәрештәләр белән сайрашсын.
Матурлыкны сөйсен, сөелсен,
Канга сусаучылыр чигенсен.
Күңелемне бер дә тыймадым,
Югалтмадым намус, иманым.
Хакыйкатьнең баргач эзеннән,
Азат иттем аны тезгеннән.

## КИЛЕГЕЗ, ШАТЛЫКЛАРЫМ

Бәхетле йолдыз астында
Тумаганмындыр инде.
Ходайдан теләк теләргә
Соңлаганмындыр инде.

Нишләсәм дә, кайгыларым
Саклап тора янымда.
Килегез, кил, шатлыкларым,
Дәва булып җаныма.

Сүнгән күңелем терелер
Җырым торса яңгырап.
...Газиз улымны сагынып,
Гомерем үтә каңгырып.

## КАРА БОЛЫТ

Баш өстемдә кара болыт
Яшергән кояш нурын.
Кара болыт асларында
Яшәүләре бик кыен.

Шомлы караңгылык баскан
Урам, ишек алларын.
Каршымда бер шәүлә йөри,
Һич тә таный алмадым.

Йөрәгем китте чымырдап,
Иңенә ачык капкам.
Әллә үлеләр шәүләсе
Чечня җиреннән кайткан?

## ЙОМГАК ЯСЫЙМ

Кайчагында үткәннәргә караш ташлыйм,
Гомеремнең агышына йомгак ясыйм.
Әрни күңел, сыкрап-сыкрап тибә йөрәк,
Файда иткән көнем илгә, һай, бик сирәк.

Ничек кенә һәрбер көнем, һәр сәгатем,
Халкым өчен файда итсен һәр гадәтем?
Туган җирне мин утырткан гөл бизәсен,
Бар әле, бар ул гөлләргә су сибәсем.

## ЯРАТ

Ярат син туган йортыңны,
Ярат ата-анаңны.
Яшьтән аерырга өйрән
Яхшылыктан яманны.

Ярат туган мәктәбеңне,
Якын дус күргән өчен.
Ярат укытучыларны,
Аң-белем биргән өчен.

Яратып эшлә эшеңне,
Ярат туган телеңне.
Кадерле изге Җиреңне,
Сый-хөрмәт ит илеңне.

Яратсаң туган халкыңны,
Күңелләрең яктырыр.
Хәерле көн теләп, чишмә
Шифа суын арттырыр.

## ТУГАН ТЕЛ

Рус телен өйрәнсәң дә,
Туган телең онытма.
Туган телемдә сөйләшсәм,
Көләрләр, дип курыкма.

Туган телен онытмаган
Руслардан үрнәк ал.
Рус теле — шикәр булса,
Туган телең май да бал.

Әллә күпме миллиард халык
Сөйләшә үз телендә.
Тел — әткәң, әнкәң бүләге,
Мәңге сакла күңелеңдә.

Телебезне үстермәсәк,
Яшәрме соң милләтем?
Тел — милләтем сандугачы,
Сандугачсыз — без ятим.

## БИЗДЕРГӘН ТАУ

Һаваланып, очынып,
Кар тузаны очырып,
Очып кош кебек кенә
Вил таудан төшеп килә.

Җил озата сызгырып,
Ак мамыклар туздырып.

Чаңгылар алып китәр,
Абыйсыз калыр Мохтар.

Чаңгы артыннан чаба,
Туктатырга юк чара.
Биздергән тау — биек тау,
Мохтар чаба: һау да һау!

## «СУГЫШ» УЕНЫ

Малайлар малай булмый ул
«Окоп» казып ятмагач.
«Дошман»ына кар йомарлап,
«Гранаталар» атмагач.

Разведкага барган булып,
Качып-посып йөрмәгәч,
Каршы якның «хәрби» серен
Әллә кайчан белмәгәч.

Җиңәрбез, җиңелмәбез, дип
Кайгырмагач ут йотып.
«Ура!» дип алга чапмагач,
Юкагач мылтык тотып.

Карлар эреп, чалбарыңның
Балаклары катмагач.
— Әткәй, әнкәй ни әйтер? — дип,
Курка-өркә кайтмагач.

Андый уен уйнамаган
Малайлар сирәк була.
Батырлык та, тапкырлык та
Тормышта кирәк була.

## ДЕСАНТЧЫ

Хезмәт вакытын тутырып,
Авылга кайтты егет.
Уң ягында аксельбанты
Чалкан яткан ай кебек.
Кулбашында зәңгәр пагон,
Башында зәңгәр берет.
Малайларның күзе кыза
Солдат егетне күреп.
Түшендә медале дә бар,
Яхшы хезмәт иткән ул.
Хәрби һава көчләренең
Десантчысы икән ул.
Шатланып кайтып килә ул,
Сагындырган туган җир.
Ярый әле, иген игеп,
Исән яши туган ил.
Югары оч малайлары
Артыннан калмый атлый.
Мәктәпкә борылды солдат,
Мәктәпкә хөрмәт саклый.
— Сабакташыбыз кайткан! — дип
Мәктәп гөжләде генә.

(Бер матур кыз гашыйк булды,
Егет сизмәде генә.)
Үзеннән үзе кузгалып,
Башланып китте бәйрәм.
Үзең укыган мәктәпнең
Бар җирен күреп әйлән.
Малайлар китерде шунда
Завод кирпече табып.
Әлбәттә җыелды монда
Кызыксынучы халык.
Бер генә сукты кирпечкә
Кулының сырты белән,
Кирпеч икегә ярылды,
Менә кем ул пәһлеван!
Пыяла шешә урталай
Кылт итеп кенә куйды,
Малайлар нишләргә белми —
Күзкәйләре ут булды.
Абыйларыннан күрмәкче
Карадылар тотынып.
— Ник безнең кулдан килми? — дип,
Уйлаштылар утырып. —
Десантчылар көчле икән,
Без дә десантчы булыйк.
Киләчәгебез хакында
Егетләр, алдан уйлыйк!

## ГАРМУН УЙНЫЙ КЫЗ БАЛА

Көмеш тавышлар чыгарып,
Гармун уйный кыз бала.
Басмагына катырак бас,
Бармакларың кызганма.

Су буйлап ерак тарала
Гармуныңның моңнары.
Абыең да уйнар иде,
Исән булса куллары.

Абыең кайтты сугыштан,
Гармунчы ул тумыштан.
Керфегендә яшь бөртеге,
Күңелләре тулышкан.

Чечняда кулы өзелгәч,
Абыең калган һушсыз.
Төшләрендә гармун уйный,
Яши алмый ул шунсыз.

Син уйнасаң дәртле көйләр,
Күңелләре ачылыр.
Йөрәгенең әрнүләре
Аз булса да басылыр.

Тартып, сузып уйна, сеңелем,
Чәчәкле күрекләрен.
Күңелләрен күтәр әле
Ветеран егетләрнең.

## СОҢГЫ КЫҢГЫРАУ

Аккош кебек ак канатың җәеп,
Иртәләрдә каршы алдың син.
Игелегең белән мәңгелеккә
Күңелләргә уелып калдың син.

Кушымта:

Соңгы кыңгырау,
Язгы кыңгырау,
Кайтырбыз юллар
Булса да урау.

Син булганда дуслык, белем иле,
Без көчлеләр, бөркет кебекләр.
Кичә генә бала-чага идек,
Хәзер җиткән кызлар-егетләр.

Кушымта.

Соңгы кыңгыраулар чыңлаганда,
Ярсып тибә икән йөрәкләр.
Сау булыгыз, укытучыларым,
Без үстергән гөлләр, чәчәкләр...

Кушымта.

Бездән соң да балаларың белән
Гөрләп яшә, туган мәктәбем.
Барлык теләкләргә ирештерер
Изгелегең синең, шәфкатең.

Кушымта:

Соңгы кыңгырау,
Язгы кыңгырау,
Кайтырбыз юллар
Булса да урау.

Соңгы кыңгырау,
Көмеш кыңгырау,
Кайтырбыз юллар
Булса да урау.

ХУШЛАШУ

Яшенле яңгыр яумыйча
Кыш аерылмый җәйдән.
Хушлашабыз мәктәп белән,
Бүген безнең зур бәйрәм.

Кушымта:

Имтиханнарны тапшырып,
Сират күперен үттек без.
Туган мәктәп кочагында
Туганлашып үстек без.

Кушымта.

Колакларда кыңгыраулар
Сандугач булып сайрый.
Күзләрдә моң, йөрәкләрдә
Сагыш утлары кайный.

Кушымта.

Укытучыларыбызга
Җырлар бүләк итәбез.
Еракларга китсәк тә без,
Сагынып кайтып җитәрбез.

Кушымта:

Алда бардыр әле яңа үрләр,
Сират күперләре кичәсе.
Мәктәп тарихына кереп калыр
Безнең чыгарылыш кичәсе.

## ИГЕНЧЕ БУЛЫРМЫН

Сикереп торып, күзем ертып,
Киттем әти янына.
Трактор тавышы таныш,
Гөрли урман ягында.

— Мен, улым, — ди, — кабинага, —
Әтием мине күреп.
Көрәк кебек кулы белән
Аркамнан сөйде көлеп.

Тузан бөртекләре кунган
Әтиемнең битенә:
— Төгәллибез, — ди сөенеп, —
Чәчүне төш җитүгә.

Язгы көн ел туйдыра, дип
Бабайлар белеп әйткән.
Көн-төн эш кайный басуда,
Күпме җир чәчкән эткәм!

Тракторларның эше күп:
Сөрә, тырмата, чәчә.
— Рәхәт яшим дисәң, улым,
Җирне яратып яшә.

Үскәч, бәлки, минем кебек
Тракторчы булырсың.
Үзең чәчкән басуларның
Уңышын күз урырсың.

Үтә тузанлы, авыр дип
Курыкма җир эшеннән.
Пакьтән пакь ул, тәмле ис юк
Пешкән икмәк исеннән.

...Яшел хәтфә каплар җирне
Тиздән, атна-ун көннән.
Тракторчы булмый калмас
Икмәк кадерен белгән.

## КАЕН КӨЧ АЛА КАЯН?

Каплап алган кара болыт,
Күк белән Җир тоташкан.
Котырына салкын җилләр,
Әйтерсең лә саташкан.

Карлы, бозлы яңгыр ява,
Көн юеш, үтә салкын.
Яланда бер каен үсә,
Яфраклары ут-ялкын.

Айкала ул, чайкала ул,
Сыгыла җиргә тиклем.
«Харап була!» дип торганда,
Торып баса ул, мескен.

Ыжгыра җил, сызгыра җил
Карлы яңгыры белән.
Йолкып атмакчы каенны
Төбе-тамыры белән.

«Газаплама каенны!» — дип,
Кычкырам ачы җилгә.
Агачның көче — тамырда,
Береккән туган җиргә.

## ТЕРСӘКНЕ БУЛМЫЙ ТЕШЛӘП

— Тупсага утыра күрмә,
Үсми калырсың, балам.
Еллар үткәч кенә белдем,
Хак сүзләр әйткән анам.
Ә мин, юләр, тыңламадым,
Тәрәземне ачтым да
Кычкырам, җырлыйм, сөйләнәм,
Тупсасына бастым да.

Биимен дә, сикерәм дә,
Чәбәкәй чапкан булам.
«Артист!» дип көлә малайлар,
Яңгырап тора урам.
Тәгәрәп төштем бер мәлне
Өй алды бакчасына.
«Ох!» диделәр, «ах!» диделәр
Малайлар барчасы да.
Әнием чыкты йөгереп,
Йөзе ап-ак көл кебек.
Елап җибәрдем, кан чыккач,
Биткә ботак төртелеп.
Әллә зәхмәт кагылдымы,
Буем үсмәде нишләп?
Әни сүзен тыңлар идем,
Терсәкне булмый тешләп.

## БЕЗНЕҢ ИНГЕЛ

Бер дигәнче биш төрлегә
Әйләнә безнең Ингел.
Йә китабын ялап ала,
Йә тешләп тарта җиңен.

Йә каләмен чәйни тәмләп,
Бармагын имеп туйса.
Мәзәкләр күп табар сымак
Дуслары көлеп куйса.

Чирек бетте. Ингел тыныч,
Йоткан ул гүя телен.
Нишләсен соң: шук малайны
Читләтеп үткән белем.

## ЗӘНФИРӘ КИТАП УКЫЙ

Кем ачуланмас Нәсимгә,
Һич тыңламый әнисен.
Көне-төне шахмат уйный,
Әзерләми дәресен.

Йомыш кушсаң, тик кул селти,
Янәсе, шахмат мөһим.
Уенга алданып, эштән
Салкынаюы мөмкин.

Китапка чумып Зәнфирә,
Укуын гына белә.
Хикәядәге Нәсимне
Әрләп ташлыйсы килә.

Шулчак әнисе: «Кызым, — ди, —
Су гына алып керче.»
Тагын әйтә, тик Зәнфирә
Баш кына кага, күрче.

Кабатлый ул: «Зәнфирә, дим»...
Кыз укый бирә һаман.
Әнисе чиләкләр асып,
Китә чишмәгә табан.

...Ә Зәнфирә китап укый
Онытып бар дөньясын.
Өстәвенә киңәш бирә:
— Әниеңне тыңла син!

## ИКЕСЕ ДӘ МАТУР КЫЗ

Песиемнең баласы бар,
Икесе дә матур гына.
Тик тормыйлар, тоттырмыйлар,
Чабышалар тыз да быз.

Өлкәне Даша исемле,
Маша инде кечесе.
Икесенең арасында
Кечесе иң көчлесе.

И уйныйлар кызык табып,
Тамаклары тук булгач.
Аналарына күңелле —
Балалары шук булгач.

Әле меңәләр сикереп
Йомшак мендәр өстенә.
Стенкада алар хужа,
Булсалар да кечкенә.

Берсен берсе җиңәбез дип,
И көрәшкән булалар.
Еламыйлар, тырнашмыйлар,
Чөнки алар — туганнар!

## СЫЕРЧЫК БАЛАЛАРЫ

1

Сыерчыкның — матуркайның
Төн йокысы бар микән?
Суалчанны эләктереп,
Таңда кайтып та җиткән.
Балалары чыр-чу килеп,
Тезелешеп басканнар.
— Ачыктык, әни, ашат, — дип,
Авызларын ачканнар.
Әниләре җәһәт кенә
Кереп чыга ояга.
Секунд эчендә җим биреп,
Очып күздән югала.
Көн буена, санап торсаң,
Ничәмә очыш ясый.
Балалары булганына
Сөенеп җимнәр ташый.

2

Шомырт ботагына басып,
Каранып тирә-якка,
Саескан, чәүкәләр килеп,
Аңдышалар кайчакта.
Андый мәлне сыерчыклар
Ташлана дошманына.
Чыпчыклар җебегән түгел,
Булыша дусларына.

Бу юлы да шулай булды:
Килде саескан — карак,
Сыерчыкның оясына
Зур өмет белән карап.
Сыерчыклар һөҗүменнән
Котылды карак чак-чак.
Ата-ана балаларын
Алып калдылар саклап.

3

Берчак кошлар кайтмадылар,
Җимгә киткәннәр иде.
Сабыйлары елый-елый
Ризык көтәләр инде.
Өч көн үтте, өч төн үтте,
Сыерчыклар юк та юк.
Чыелдашып, ризык көтеп,
Балалары йота ут.
Гаепсез бичараларның
Кемнәр өзгән гомерен?
Ачы язмышларын күреп,
Әрни минем күңелем.
Күрәм: чыпчыклар җыелып,
Чыркылдашып алдылар.
Шактый озак «бәхәсләшкәч»,
Туктап, тынып калдылар.
Берсе менеп башын тыкты
Сыерчык оясына,
Кошчыкларның исәнлеген
Тикшереп чыга сыман.

Берничә чыпчык очты да
Әйләнеп кайтты кире.
Авызларында бик симез,
Бик зур суалчан иде.
Күрмәгән булсам бу хәлне,
Язмас идем бу хакта.
Кошларның да асылында
Изге теләкләр ята.
Тәмле ризыклар китереп,
Ашата кошкайларым.
Күрермен бала кошларның
Оядан очканнарын.

## АВЫЛГА БАРЫЙК, ДИЛӘР

Балаларны булмый тыеп,
Авылга барыйк, диләр.
Ямьле җәйдә авыл матур,
Шәһәрдә калмыйк, диләр.

Әнием, авылыбызның
Һавасы тансык, диләр.
Яланаяк йөрер идек
Чирәмгә басып, диләр.

Нәнәебезне сагындык,
Күрәсебез бик килә.
Безне сыйлар каймак, катык,
Яңа сауган сөт белән.

Болыннан алып кайтырбыз
Кайтмый калган малларны.
Сыерның сөтен саварбыз,
Ял итәр ул аннары.

Бәбкәләрне яратабыз,
Матурлар чирәм кебек.
Карга, тилгәнне куабыз,
Урламасыннар килеп.

Авылда эш бетәмени,
Утау да утыйсы бар.
Елгада балык шәп, диләр,
Балыклар тотасы бар.

Көн кыздыргач, яр буенда
Су чәчрәтеп уйнарбыз.
Саф һавада, киң болында
Уеннан һич туймабыз.

Авыл малайлары белән
Күптән дуслаштык инде.
Дуслашып кына калмадык,
Көч тә сынаштык инде.

Нәнәй әйтә:
— Сез килгәнгә
Өебез ямьләнде, — ди. —
Яшел печән ашаганга
Сөтебез тәмләнде, — ди.

Дәү әтиебез аркадан
Шап та шоп итеп сөя.
Үзе шатлана, үзенең...
Күзләреннән яшь килә.

## ТЕПЛОВОЗ

*В. Хәбисламов көе*

Ашыкма, тепловоз,
Азга, бик азга түз.
Перронда бер яшь кыз
Төшерде миңа күз.

Кушымта:

Тепловоз, тепловоз,
Китмәче, китмәче.
Йөрәгемә ут сипмәче,
Килче, килче яныма, сылу кыз.

Кайчандыр электән
Танышлар идекме,
Әллә соң вагонда
Без бергә килдекме?
Агыйдел суларын
Кичтекме бергәләп,
Чал Урал тавына
Мендекме үрмәләп?

Кушымта.

Ярсыган күңелемне
Ах, ничек түздерим.
Машинист кычкырта,
Кычкырта өздереп.
Кузгала тепловоз,
Миңа кул сузыла.
Охшаттым Дон кызын
Иделем кызына.

Кушымта.

## КӨТӘМ

Шомыртлар чәчәк аттылар,
Манчылам исләренә.
Чәчәкләрдәй сылу кызлар
Яшиләр Истәгемдә.
Кайсысын белмим сайларга,
Берсеннән берсе чибәр.
Бөдрә чәчле Саниясе
Аш-суга маһир, диләр.
Фәнисәне дә мактыйлар
Җыр-биюгә оста, дип.
Шулаен шулайдыр ла ул,
Буе-сыны кыска бик.
Төскә-биткә матур икән
Укытучы Нурсафа.

Ай саен акча ала, ди,
Өйләнимче, булмаса.
Йортлы, машиналы булам
Гөлйөземгә өйләнсәм.
Бәхеткәем булыр микән
Яратмасам, сөймәсәм.
Нәрсә уйларга да белми
Саташып бетәм инде.
Миңа язган бәхет кошым
Килер, дип көтәм инде.

## ЧӘЧӘКЛӘР

Әйтегез, чәчәкләр,
Кем сезне үстерде,
Күңелне яуларлык
Илаһи көч бирде.
Күр, нинди чәчәкләр
Тирбәлә җилләрдә.
Мин телим иркәмне
Чәчәккә тиңләргә.
И, гүзәл, яшь парлар,
Аерылып китмәгез.
Өзелгән гөлләрдәй
Саргаеп кипмәгез.

## ТАМЧЫЛАР

Тамчылар тыпылдап
Тау-ташны тишәләр.
Күңелләр төенен
Бергәләп чишәләр.
Тамчылар бәгыремнең
Кылларын чиртәләр.
Ашыкма, килер көн —
Сөйгәнең иркәләр.
Тамчылар нур чәчеп
Җемелди үләндә.
Өзелмә тамчыдай,
Бер сөям дигәнгә.

## ЙОЛДЫЗЛАР — КҮРӘЗӘЧЕ

Нинди язмыш көтә икән
Буйга җиткән кызларны?
Җиткән кызлар сердәш итә
Җидегән йолдызларны.

Җиде төн урталарында
Йолдызлар яна күктә.
Җидегән йолдызны күрсәң,
Теләк теләми үтмә.

Җидегән йолдызны сана,
Бер түгел, җиде кабат.
Сөйгәнең калмасын ятка,
Карат үзеңә, карат.

Җидегән йолдызны санап,
Мендәргә сал башыңны.
Төшләреңдә син күрерсең
Киләчәк язмышыңны.

Гомерлек ярың булырмын,
Керсәм татлы төшеңә.
Йолдызлар — күрәзәче ул
Гашыйк булган кешегә.

## КҮК ЧӘЧКӘЛӘРЕ

Йолдызлар — күк чәчкәләре,
Гашыйклар күреп чүпләр.
Йолдызлардан Җир өстенә
Сузыла көмеш җепләр.

Тылсымлы моң шул җепләрдән
Иңәме әллә Җиргә?
Чың-чың итеп матур көйләр
Җаныма үтеп керә.

Бәрхет тавыш дулкынында
Йөрәк тибә җиңелчә.
Һәр йолдызның үз моңы бар,
Үз нуры бар, минемчә.

Яратышып яшәсеннәр
Җир белән Күк гел шулай.
Табигатьне парлы итеп
Яраткан Тәңре-Ходай.

...Синең дә күк күзләреңнән
Агыла моңлы нурлар:
Йөрәгемне йөрәгеңә
Тоташтырган ак юллар.

## ҖИЛӘКЛӘР ПЕШКӘН ИДЕ

Җиләкләр пешкән иде,
Өзелеп төшкән иде.
Мин җыясы җиләкләрдән
Күптән җил искән иде.

Җиләк җыялмам инде,
Кагын коялмам инде.
Җиләктәй иреннәреңне
Үбеп туялмам инде.

## ЧӘЧӘКЛӘР УТЫРА ТЫН ГЫНА

Яфракка кагыла-кагыла
Моңлы җыр агыла-агыла.
Җәйге зур бакчада тик икәү
Сөйләшә җай гына, җай гына.

Түтәлдә чәчәкләр, чәчәкләр
Үзара сыена-сыена
Яшь парны таңгача, таңгача
Тыңларга җыена-җыена.

Тулган ай төн буе, төн буе
Ак нурлар сипмәкче, сипмәкче.
Гашыйкларны назлап, сандугач
Җыр бүләк итмәкче, итмәкче.

Күкрәкләр күкрәккә кысыла,
Кушыла иренгә иреннәр.
Сандугач, ай йома күзләрен,
Алар бит фатыйха бирделәр.

Чәчәкләр утыра тын гына,
Йөрәкләр талпына, талпына.
Мөмкинме вәгъдәләр бирмәскә
Бәхетле киләчәк хакына?

## ТУКТАП ТОРЫЙК, ТЫҢЛАП ТОРЫЙК

Әйдә әле, урап кайтыйк
Кырларны, тугайларны.
Туктап торыйк, тыңлап торыйк
Сайравын тургайларның.

Кушымта:

Эштән бүтәнне белмисең,
Сөйләшмисең, көлмисең.
Башкалардан кай җирем ким,
Син үзеңне кем дисең?

Буә ярларына басып,
Карыйк су агышларын.

Туктап торыйк, тыңлап торыйк
Шаулавын камышларның.

Кушымта.

Йөрик әле урамнарда,
Мине ялгыз итмәле.
Туктап торыйк, тыңлап торыйк
Йөрәкләрнең типкәнен.

Кушымта.

## КИҢӘШ

Бер кыздыра, бер туңдыра,
Битләрем яна уттай.
Карашларым бер ноктага
Кадалган аткан уктай.

Берчә тамыза күзләрем
Яшьләрнең иң кайнарын.
Күкләргә ашкан күңелем
Очып йөри кайдадыр.

Китте, югалды тынычлык,
Бимазалана җаным.
Тәнемнән чыгардай булып,
Ургыла, кайный каным.

Әйләндеме башым ташка,
Нәрсә дә уйлый белми.

И котырына хисләрем,
Акылга ирек бирми.

...И үсмер, аңларга тырыш
Үзеңнең халәтеңне.
Беренче мәхәббәт сыный
Яшәргә сәләтеңне.

## ҖИТЕП КИЛӘ АЛМАСЫ

Алмагачның алсуланып,
Җитеп килә алмасы.
— Яшь бит әле, өзмәгез! — дип
Йөгереп чыккан анасы.

Соңга калырга ярамый,
Өлгерә ул җылытсаң.
Егетләрнең ут шикелле
Кайнарына юлыксаң.

Тәмам өлгереп җитте исә,
Утсыз януы да бар.
Алмалар кыска гомерле —
Ялгыз калуы да бар.

## ЯННАРЫҢА БАРЫРМЫН

Яннарыңа барам әле
Йомшак җилләр искәндә.
Таң нурларына коенып,
Гөл-чәчәкләр үскәндә.

Күкрәгемдә дәртем таша,
Йөрәк ярсып типкәндә.
Сиңа атап җыр җырладым
Турыгыздан үткәндә.

Тавышларымны ишетеп,
Мине каршы алырсың.
Күңелеңдә бер моң булып,
Мәңгелеккә калырмын.

Син килмәсәң, җырлый-җырлый
Яннарыңа барырмын.

## МИН — ЯҢАВЫЛ БАЛАСЫ

Яңавыл-Уфа арасын
Җырлап кына барасы.
Сөйгән ярым Уфа кызы,
Мин — Яңавыл баласы.

Кушымта:

Алма сата, хөрмә сата
Башкала кибетләре.
Уфалылардан ким түгел
Яңавыл егетләре.

Машина тәгәрмәчләре
Майламасаң әйләнми.
Сөйгәнемә барам әле,
Бер күрүе әллә ни.

Кушымта.

Аралар ерак булса да,
Күңелләр якын гына.
Яна йөрәккәем, яна
Мәхәббәт ялкынында.

Кушымта.

Вәгъдәләштек туй ясарга
Язгы сабантуенда.
Килегез безгә кунакка
Ямьле Бүә буена.

Кушымта.

## УТТА ЯНАМ

Сине күрсәм утта янам,
Бер сүнәм, бер кабынам.
Мин дә адәм баласы бит,
Матурлыкка табынам.

Зифа буйларың килешле,
Гәүдәң сыгылып тора.
Кочаклап бер үбәр идем —
Җитми кыюлык кына.

Сине көтеп таң аттырам,
Янам да көям инде.
Сандугач булып сайрармын,
Аңласаң йөрәгемне.

## БӘЛКИ, ГАФУ ИТӘРСЕҢ

Аерылып киткәч тә, арттан
Килерсең, дип уйладым.
Ялынырыңа ышандым,
Тик беркатлы булганмын.

Икебез ике утрауда,
Арабызда дулкыннар.
Йөгереп кире кайтыр идем,
Юлларымда упкын бар.

Үземне әллә кем күреп,
Хаталанганмын икән,
Әче телләнеп, сине гел
Җәфалаганмын икән.

Миннән башка кыен булыр,
Ничек дөнья көтәрсең?
Йөрәгең таш түгелдер бит,
Бәлки, гафу итәрсең?

## ШАЯРУ

Алъяпкычың бәйләп алдың да син,
Җиңнәреңне куйдың сызганып.
Табаларга вак-вак коймак тездең
Таң нурлары кебек кызарып.

Әллә оялыпмы, әллә юри
Күзләреңне миннән яшердең.

— Уңайсыз ла, син каршымда торгач,
Уф йөрәгем, бетте, пешермим.

Мин сокланам: «Иркәм, бит очыңа
Он буялган, нинди матур!» — дип.
Күзләремне ала алмыйм синнән:
Каян килде шундый батырлык!

## МӘХӘББӘТЕҢ БУЛСА

Мәхәббәтең булса, шундый булсын —
Бер-береңнең кадерен белерлек.
Күкрәгеңдә дәртең ялкынлансын,
Алтын туеңда да биерлек.

Мәхәббәтең булса, шундый булсын —
Тормыш матурлыгын күрерлек.
Өй тутырып бала үстерерлек,
Бәхет таҗын бергә үрерлек.

Мәхәббәтең булса, шундый булсын —
Җыермасын кара кашларын.
Өмет белән киләчәккә карап,
Яңартырсыз нигез ташларын.

Мәхәббәтең булса, шундый булсын,
Ил язмышын күтәр җилкәңдә.
Гомер юлларында сынатмассыз
Йөрәкләрне парлап җиккәндә.

## ЯТСЫНМА

Хисләрем чишмәсе ургылып,
Ашкынып акканга пошынам.
Елгага, диңгезгә җитмәстән
Корыса, нишләрмен, дускынам.

Шундый саф һәм кайнар чишмә ул,
Көннән-көн агымын арттыра.
Якын дус, тизрәк бул, тизрәк бул,
Шифалы суын эч, ятсынма.

Икебез гел бергә булганда
Әйтерсең үзең дә, ышанам:
— Хисләрең кайнар да, ярсу да,
Нәкъ менә гейзерга охшаган.

## КАЙДА МИНЕМ МӘХӘББӘТЕМ?

Кайда, кайда минем мәхәббәтем,
Тургай булып күктә сайрыймы?
Бал кортлары сыман, юллар үтеп,
Кунар өчен чәчәк сайлыймы?

Кайда, кайда минем мәхәббәтем,
Алып барыр нинди юл гына?
Тирбәләме әллә күл өстендә
Ялгыз аккош сыман тын гына?

## ЯШЕРМӘ КАРАШЫҢНЫ

Яшермәле каршыңны
Күзләрең йомып кына.
Кояш нурларын яшерә
Караңгы болыт кына.

Очкыны төште бәгырьгә
Керфегең арасыннан.
Кояштан да якты булып,
Йөрәгем яна сыман.

Дөньяның бар гүзәллеген
Күзләреңә җыйгансың.
Туйганчы бер карыйм әле,
Күңелләрем куансын!

## ТЕЛЕВИЗОР

*(Җыр)*

Телевизор карап кына
Күзләрем талмас әле.
Бер дикторга гашыйк булдым,
Гаепкә алмас әле.

Кушымта:

Телевизор, телевизор —
Замана могҗизасы.
Бөтен дөнья уч төбемдә,
Илләрне юк гизәсе.

— Хәерле иртә! — дип дәшә,
Каршыма килеп кенә.
Нур өстенә нур өстәлә,
Сөйләгәч көлеп кенә.

Кушымта.

Күзләре кара бөрлегән,
Кыйгач кара кашлары.
Әллә кайчан күргән булсам,
Сөймәс идем башканы.

Кушымта.

Уфа дикторлары кебек
Матур кызлар бар микән?
Белсәң иде, телләрендә
Шикәр микән, бал микән.

Кушымта.

## ЯШЬ ПАРГА

*(Шаяру)*

Китап сүзе сөйләрмен, дип
Килмәдем мин бәйрәмгә.
Тик шулай да тел очымда
Матур сүзләр әйләнә.
Шушы олугъ туегызда
Дәшми калмам, кәнишне.

Җиңгәң әйтә:
— Кистереп әйт,
Башкалардан калышма.
Түбәңнең ак чәчкәләрен
Түбәтәеңә яшер.
Егетләрчә тот үзеңне,
Өлкән булса да яшең.
Ялыктырма кунакларны
Озын-озак тел чарлап.
Түшәмгә карап сөйләмә,
Сөйлә яшь парга карап.
Һәрчак безне шатландырды
Уңышлары яшьләрнең.
Хәзерге заман яшьләре
Кадерен белә яшәүнең.
Пар килгәч тә килер икән
Улым һәм киленебез.
Битегезне чәпелдәтим,
Миңа якын килегез.
Киленкәйнең чибәрлеге
Үтерә инде менә!
Итәгемнән тарта җиңгәң:
— Сөйлә кирәген генә.
Тиң мәхәббәт, бәхет телә
Гөлназ белән Фәниткә.
Тормышта сынатмасыннар,
Җиңгән сыман һәр эштә.

## КЫЗЛАР ҮТЕП БАРА

Көлешә-көлешә кызлар үтеп бара,
Күзләремне уттай яндырып.
Кычкырасым килә: «Туктагыз! — дип, —
Китмәгез, — дип, — мине калдырып».
Уктай атылып, өйгә кереп чаптым,
Алыштырыйм өстем, башымны.
Уф, йөрәгем, типмә шулай ярсып,
Хәтерләтеп язгы ташкынны.
Кызлар арасына керермен дә,
Култыклашып бергә атлармын.
Әйләндерә башны хушбуй исе
Фәрештәдәй асыл затларның.
Риза булса, бәлки бер гүзәлне
Өенә кадәр озата бармын.
Шомырт чәчәкләрен бүләк итеп,
Таңга кадәр шунда калырмын.
Үпкәләтми генә, назлап кына
Нечкә билләреннән кысармын.
Җанны эретер кайнар иреннәре...
Бу рәхәткә ничек чыдармын?!
Битләремне иркәләсен әле
Дулкын-дулкын ефәк чәчләре.
Рәхмәт инде сезгә, сылу кызлар,
Сезне күргәч, күңел яшәрде.
...Көлешә-көлешә кызлар үтеп китте,
Йөрәгемне уттай яндырып.
Их, картлыгым, нигә иртә килдең,
Гүзәлләрне ятка калдырып?!

## КӨНЛӘШҮЕҢ ҮТӘ ҖИЛЕГЕМӘ

Көнләшүең үтә җилегемә,
Авызыңны үлчәп ачмыйсың.
Эштән кайткан саен «син фәлән» дип,
Ялган гаепләүләр ташлыйсың.

Ничек оялмыйсың көннәр буе
Урам буйлап гайбәт җыярга?
Ашыкма син кара елан булып
Керсез хисләремне буарга.

Кабат-кабат кайт син яшьлегеңә,
Вәгъдәләшкән таңны хәтерлә.
Мәҗбүр итмәдем бит «Мәңгелеккә
Мин синеке!» диеп әйтергә.

Миннән башка рәхәт булыр, димә,
Мәшәкатең артыр бермәбер.
Алтын сарайларда яшәсәң дә,
Ялынычың төшәр кемгәдер.

Гаиләнең ныклыгын теләсәң,
Бозык уйларыңа хуҗа бул.
Эт-мәчеләр кебек яшәгәнгә
Гомеркәйләр зая уза ул.

## КҮҢЕЛЛӘРДӘ ЯЗ БУЛА

Дөнья булгач, явар әле
Яңгыры да, кары да.
Ир хакын хаклый гомергә
Яшьли сөйгән яр гына.

Көйсезләнгән чакларыңда
Акыллы киңәш бирер;
Эшләрең алга барсын, дип
Үзе булышып йөрер.

Өлгерер ул кирәк чакта
Иркәләп юатырга.
Кем теләр бәхет ачкычын
Төшереп югалтырга.

Бер-берсен сөйгән ярларның
Күңелендә яз була.
Сөйләшер сүзләр булса да,
Төчеләре аз була.

## УРАМДА КУНАСЫҢМЫ?

Йөремә әле каңгырап
Тәрәзәм тирәсендә.
Үзәкләремне өзәсең
Каршыма киләсең дә.

Көтмә, зинһар, өмет итмә,
Чыкмыйм күпме көтсәң дә.

Өй тирәсендә әйләнеп,
Сукмак салып үтсәң дә.

Мине көтеп, янып-көеп
Урамда кунасыңмы?
Чыкмасам да беләм инде
Минеке буласыңны.

## САНДУГАЧ ТЫНГАН ИДЕ

Икәү бергә йөргән идек
Каймаша болынында.
Ак чәчәкләр тезеп чыктың
Чем-кара толымыңа.

Хуш исле гөлләр диңгезе
Дулкынлана җилләрдә.
Якында сайрый сандугач,
Кәккүк көйләп җибәрә.

Җәйнең җиткән кызлар кебек
Купшы киенгән чагы.
Кайда басканын да белми,
Биеп сөенгән чагы.

И җиңел иде аяклар,
Хәл беткәнче йөгердек.
Хисләр ташып, кочаклашып,
Чәчәкләргә күмелдек.

Печәннәре уңган иде,
Хуш искә тулган иде.
Якында кәккүк кычкырды,
Сандугач тынган иде...

## КӨЗГЕ ВАЛЬС

Сары яфраклар коела
Тирбәлеп, бөтерелеп.
Туйганчы биик, дусларым,
Булмасын үкенерлек.

Тылсымлы вальс моңнары
Еш яңгырый көзләрен.
Вальс моңнарын ишетсәм,
Биемичә түзәлмим.

Ак каеннар басып тора,
Ямьле җәйне сагынып.
Әйләнер сыман вальска
Алтын шәлен ябынып.

Яшь-җилкенчәк уйный-көлә,
Гөр килә кичке мәйдан.
Дәртле яшьләрне сәламләп,
Зөһрә кыз көлә айдан.

Вальс моңы җилкендерә,
Ашкындыра йөрәкне.
Син булганга мин бәхетле,
Башка беркем кирәкми!

## МӘХӘББӘТ

Сүндереп була утларны,
Суларны бүлеп була.
Бер атыла да вулканнар,
Бер туктап, сүнеп тора.

Тик мәхәббәт бар көчләрдән
Өстен бит ул, дусларым.
Әйтегезче мәхәббәткә
Буйсынмаган кем барын?

Мәхәббәт ташкыннан көчле,
Кайнар уттан, ялкыннан.
Үзе күренми ул күзгә,
Ул — фәрештә затыннан.

Миллион еллар үтеп киткән, —
Мәхәббәт искермәгән.
Димәк, без бар да яралган
Мәңгелек изгеләрдән.

## ТЫҢЛАРМЫН

— Җыелышка бар, — диделәр,
Бардым инде, тыңладым.
Халыклар таралган иде,
Соңладым шул, соңладым.

Мәҗлескә эндәштеләр,
Бардым инде, тыңладым.
Кунаклардан җилләр искән,
Соңладым шул, соңладым.

Кызлар уенга чакырды,
Бардым инде, тыңладым.
Кияүгә китеп беткәннәр,
Соңладым шул, соңладым.

Соңгы юлга эндәшсәләр,
Бармый калмам, тыңлармын.
Гадәтем сеңгән каныма,
Соңлармын шул, соңлармын.

## НӘФСЕ

Атым үргә менә алмый,
Тиргә батты, бахырым.
Нәфсемә булышкан булып,
Төягәнмен артыгын.

Печәне җиләк кенә шул,
Чәйгә салып эчәрлек.
Әйдә, малкай, кузгала күр,
Тарт тагын бер көчәнеп.

Булышыйм әле үзем дә,
Миндә дә көч җитәрлек.
Карасана, хәлем бетә,
Кая киткән җегәрлек?

Тәмам ачуым кабарды,
Сыртына салып алам.
Тик һаман йөк бер урында,
Кузгалырмы берзаман?

Төрткәләп корсак астына,
Тарткалыйм авызлыгын.
Әкрен-әкрен ат чигенә,
Куркытты явызлыгым.

Йөгем ауды, тәртәм сынды,
Бичаракай буылды.
Түшлек бавын кискәч кенә,
Үлемнән ат котылды.

...Рюмка алгач та кулыма,
Искә төшә мескен ат.
«Төямимме» артыгын, дип
Сорау бирәм ничә кат.

## БЕР ЕГЕТ

Мичәп җикте тулпарларны
Бер егет.
Әйләнеп кайтмакчы булып,
Җил җилеп.
Утырган төренеп үзе
Толыпка.
Камчысы белән атларны
«Җылыта».
Төпкә җигелгәне баткан
Күбеккә.
Нәкъ шунысы тартмаган күк
Егеткә.
Камчысы белән суктыра
Ничә кат.
Ишетмәгәнен ишетә
Мескен ат.
Уйнаклап ян-яктан чаба
Юртаклар.
Уртаклашмый авыр йөкне
Ул атлар.
Түрәнең чыкса ачуы
Кемгәдер,
Беләм, аңа ат язмышы
Эләгер.

АВЫЛ

Авыл яши арып-талып,
Очын-очка ялгый-ялгый.
Мена-мена яңарам, дип
Үзен-үзе алдый-алдый.
Авылны җыерчык баскан,
Өйләр чүгеп, авызын ачкан,
Теше төшеп протез капкан,
Колак аппараты аскан.
Авыл бөрешкән суыктан,
Җил ак кардан кибән койган.
Тәрәзәләргә боз каткан,
Котып салкынлыгын җыйган.
Язларын сайрый сандугач,
Сагышларга чут-чама юк.
Кайтмыйлар бит балалары,
Йөрәкләрдә ут яна, ут!
Авыл сагына үткәнен,
Гөрләтеп көн иткәнен.
Кыңгыраулы атлар җигеп,
Кунак, туйларга киткәнен.
Һәр авылда ун өй калган,
Шул ун өйдә унбер әби.
Ирләрдән гомер итә тик
Җитмеш яшьлек яугир Нәби.
Авыл авыру, хәлсезләнгән,
Диагнозы: картлык чире.
Кем кулына тапшырыр ул
Мирас итеп изге җирне.

## ТӨТЕН

Морҗа башыннан чыга да,
Үрмәли югарыга.
Кысык мичтән котылдым, дип,
Үзенчә куаныргa.

Җил кайдан, төтен шул якка,
Бөтерелә, болгана.
Теләсә, теләмәсә дә,
Күз алдыннан югала.

Төрле төсләргә керә дә,
Мактанган була төтен:
— Утынга янарга куштым,
Мин ут-күмердән өстен.

## ХӘЙЛӘЛӘ

Ташкын булып халык чыккан
Урамга.
Ничәмә төрле әләмнәр
Урала.

Фикерең булмаса да кычкыр,
Нотык тот.
Җиде бабаңның тетмәсен
Тетеп чык.

Үзеңне онытма, макта,
Хәйләлә.
Алдасаң да, җир барыбер
Әйләнә.

## ШУНДА МӘХШӘР ВӘ ТӘМУГ

Мәрмәрдән сарайлар салды,
Шактый мая туплагач.
Халыкның кесәсе белән
Үз кесәсен бутагач.

Машиналар гынамы соң,
Самолет алды сатып.
Үзе теләгән илләргә
Йөри ул барып, кайтып.

Яшьлеге әйләнеп кайтты,
Яшь хатын алып килгәч.
Ышанган алтын теленә,
Майда йөздерәм, дигәч.

Әшнәләре ярдәм иткәч,
Җибәрде завод салып.
«Яшел елан» концерт куя,
Шунда мәхшәр вә тәмуг.

Типтерәләр, сиптерәләр,
Байларга юллар ачык.
Бушка эшләгән халыкка
Кычкырып килә ачлык.

## ДОЛЛАР

Безнең акча акчамыни,
Олтырагы долларның.
Шул доллар кимерә инде
Илебезнең малларын.
Долларың булса, син — түрә,
Абруйлы, сүзең өстен.
Юк икән, син — гөнаһсыз зат,
Алла бәндәсе, мескен.
Ялкаулыкта гаепләнеп,
Исем күтәрә халкым.
Эш табалмый җәфа чигә,
Булса да кулы алтын.

## ОНЫТКАН

Үтәр хәл юк: кара борынын
Капка астыннан сузып,
Абалап, өреп каласың,
Тынычлыгымны бозып.
Көчек чагыңнан ук беләм,
Сый-хөрмәт итә идем.
Күзгә карап, койрык болгап,
Күчтәнәч көтә идең.
Беркайчан да рәнҗетмәдем,
Аштан мәхрүм итмәдем.
Каршы алдың, озата бардың
Эштән кайткан, киткәнне.
Аякларыма уралып,
Әйтче, күпме уйнадың,

Ай-һай юха идең мәгәр,
Нигә песи булмадың?
Хәзер гауга куптарасың,
Хуҗаң шулай кушамы?
Син кем булып чыгасың соң,
Аумакаймы, куштанмы?
Кичә нигә таягымны
Чүбекләндердең чәйнәп?
Валлаһи, үтерә идең,
Калмасам алдан шәйләп.
Ул күзләрең кып-кызыл кан,
Тешләрең кылыч кына.
Гаебем булса әйтсәнә,
Аңлашыйк тыныч кына.
Күрәм: буең үстергәнсең,
Симерүең дә җиткән.
Димәк, хуҗаң хәстәрлекле,
Өзми колбаса, иттән.
Мөгаен, легковойларда
Җилдерәсеңдер әле.
Шашлык ашап, сөякләрне
Кимерәсеңдер әле.
Яңа хуҗам шәп булды, дип
Искесен ник ташларга,
Ырламасаң кыенмыни,
Сорамый бит ашарга.
Кешеләргә гаҗәпләнмим,
Дусларын тиз оныта.
Шунысы гаҗәп, онытkансың,
Эт тикле эт булып та.

## ЙӨРӘГЕ ТОРА ҖИЛФЕРДӘП

Төн урталарында килеп,
Шакып ишек ачтырды.
— Үләм, башым ярыла! — дип,
Утка, суга бастырды.
Йокы аралаш нитмәк кирәк,
Төштем тәмам коелып.
Бертуктаусыз җикеренә,
Тормый бит һич тыелып.
Хатын әйтә: «Цитрамон да,
Аспирин да бар безнең.
Шунда, комод тартмасында,
Даруларны ал үзең».
Йөрәге тора җилфердәп,
Усак яфрагы кебек.
Ауный, тәгәри идәндә,
Борыны беткән җебеп.
— Төкеренмә, — дим, — тынычлан,
Өстең-башың карала.
Ярдәм бирсен хатыныңа
Исерек ирне карарга.
Хатын әйтә: «Чәй ясадым,
Чәй эч, башың төзәлер.»
«Үзең эч!» — дип кырт кисте бу,
Кем дип үзен беләдер.
Алмады даруларымны,
Эчмәде чәйне, түкте.
— Төлке, — дип, — саран шайтан, — дип
Туйганчы безне сүкте.

## ҖАЕН ТАПКАН

Печән йөге кебек төяп,
Кайтты Хатип утыннан.
Кай арада ир-ат кереп,
Йөк сүтәргә тотынган.
Шундый матур гадәт һаман
Яши әле авылда.
(Әйтсәм әйтим, берән-сәрән
Ялкаулар да табыла.)
Ай-һай, утынның хәтәрен
Алып кайткансың, диләр.
Каравылчының, мөгаен,
Җаен тапкансың, диләр.
Хатипнең авызы ерык,
Канәгать үз эшеннән.
Шулай булмый, авыр йөкне
Җилкәсеннән төшергән.
— Билетың булсын мөһерле,
Торсын анда ун тамга,
Башбаштакланып барыбер
Керәлмисең урманга.
Дөрес, аның коймасы да,
Тимер капкасы да юк,
Каравылчының биләндә
Патрон тасмасы да юк.
Әмма ләкин һич тә аның
Авызы кыек түгел.
Күпме бирсәң дә күтәрә,
Буыны сыек түгел.

Яланның олысы хәтле,
Күңеле иркен аның.
«Акбаш»ны күрдеме, энем
Бирә дә бирә... җанын!
Утынның нинди кирәк:
Ак каенмы, усакмы.
Сайлап ек та агачларны,
Бер читкә ат ботакны.
Шәм кебек чыршыны аудар,
Утырмасын әрәмгә.
Бар да кирәк үз йортында
Дөнья көткән адәмгә.
Саранланма, йоттырып ал
Шайтан төкергән суны.
Документыңа кул куйдыр,
Уңайла кайтыр юлны.
...Шаккатып тыңлаган була
Күпне күргән ир-атлар.
Беләм, каравылчы өчен
Һәр йорт күчтәнәч саклар.

## БАР ИНДЕ

*(Тукайча ук булмаса да)*

Банкет залларында тамак
«Чылатулар» бар инде.
Салып алган егетләрнең
Янулары бар инде.

Урманда, елга буенда
Җыелулар бар инде.
Асыл ярлар кочагында
Җылынулар бар инде.

Баш авырткач, өстәл сугып,
Кычкырулар бар инде.
Ятлар белән курортларга
Ычкынулар бар инде.

## ӨЙЛӘНДЕМ

Өйләндем тагын бер кызга,
Яратып, сөеп кенә.
Әниемә дә ошады,
Күреште көлеп кенә.

Кушымта:

И әни, әни, әни,
Бирер идем әллә ни.

Беренчесен тарткан өчен
Керетмәде ишектән.
Икенчесен өнәмәде,
Авырлы, дип ишеткән.

Кушымта:

И әни, әни, әни,
Минем йөрәгем әрни.

Матур да инде сөйгәнем,
Чәчләре, күз-кашлары.
Үзебезчә, нәкъ татарча
Сукалый да башлады.

Кушымта:

Их, әни, әни, әни,
Сөйләшүе әллә ни.

## ӘТИ БУЛДЫМ МИН БҮГЕН

Әнинең йөзе кырыс:
— Сиңа, улым, зур бурыч:
Йә легковой, йә ат тап,
Хәзер үк әйләнеп кайт.
Юкса эшләр харап, — ди, —
Сөендер, — ди, — ярабби.
Катып торма, тизрәк, — ди, —
Транспорт кирәк, — ди. —
Юлларың уң кылсын, — ди, —
Бәхете белән тусын, — ди.
Әйләнеп китте башым,
Эшне нәрсәдән башлыйм?
Хәл-әхвәлен сорыйммы?
Берәр дару сузыйммы?
И сөекле хатыным,
Түз инде, түз, алтыным.
Идарәгә барыйммы,
Фермадан ат алыйммы?

Шалтыратсам әгәр дә
Теге «ашыгыч ярдәмгә»?
Әни әйтә: — Пешмәгән,
Үз башыңа төшмәгән.
Карасаң үзең татып,
Тормас идең шаккатып.
Күз ачып йомганчы кайт,
Йә легковой, йә ат тап!
Беттем тәмам чуалып,
Мин нәкъ аудагы балык.
Нишләргә белми торам,
Үземчә план корам:
Барсам әгәр фермага,
Калмагандыр бер мал да.
Рәиснең легковоен
Сорыйм, бирер, мөгаен...
Легковой түгел, бер ат
Җигеп кайттым менә, вәт.
Мендәрләр сала-сала
Әнкәй укынып ала:
— Рәхмәтең кыл, Ходаем,
Җиңеллек бир һәрдаим.
Кара аны, улыкаем,
Изге булсын юлкаең.
Килен сабыр, акыллы,
Туктатма, ку атыңны!
Ничек итсәм дә иттем,
Роддомга барып җиттем.
Каршы алдылар бар да:
Сестралар, врачлар да.

Йөрәк кага, башым ут,
Елга тора бер минут!
«Әттәү!» дип туды балам,
Йөгереп тә китте аннан.
Үтмәгәндер бер күлем,
Әти булдым мин бүген!
Өйләнсәң әгәр, энем,
Алдан ук аяк киен.

НЛО

Каһәрең, көн кыска булгач,
Киттем төнлә мунчага.
Ләүкәдән чабынып төштем,
Кулда сабын, мунчала.
Бервакыт ишек ачылды,
— Мөнәвәрә, синме бу?!
Ул да, ул да түгел кебек,
Кешеме, таш сынмы бу?
Өстендә ал комбинезон,
Башында модный шлем.
Чалбарымны кияр идем,
Кузгалыр хәл юк, нишлим.
Туп-туры өстемә килә:
— Курыкма, син, тыңла, — ди. —
Сине эзләп күктән төштем,
Тегеннән мин, НЛО, — ди.
Күзем маңгаема менде,
Кычкырам — чыкмый өнем.

Бар икән күрәселәрем,
Әйләнмәс булды телем.
— Оялчан булып кыланма,
Чишендер, — ди, — тиз генә.
Иркәләнәсем килә, — ди...
Күңелем нидер сизенә.
Вәт әкәмәт: хатын ич бу!
Миңеннән танып алдым.
— Замана юләрләнә, дип,
Юләрләнмикче, җаным.

## ЯРАТАМ

Хатыныма да кагылды
Демократия җиле.
Авызында сигареты,
Бар дип тә белми мине.

Эштән кайта «Мерседес»та,
«Под градусом» инде.
Ничек аш-су әзерләсен,
Керемне юсын инде?

Иренемне тешләп түзәм,
Югалтмый акылымны.
Этле-мәчеле торсак та,
Яратам хатынымны.

## КҮЗЕҢ ТӨШТЕМЕ ӘЛЛӘ?

Тигәнәк түгелсеңдер,
Күләгә түгелсеңдер.
Белмим, ник минем артымнан
Тагылып йөрисеңдер.

Күзләреңне текәмә,
Тимә, зинһар, теңкәмә,
— Сине генә яратам! — дип
Китче, миңа сөйкәлмә!

Күзең төштеме әллә?
«Түбәң» күчтеме әллә?
Мин бит, энем, ир хатыны,
Кызлар төслемен әллә?

## БӘХЕТ КИЛДЕ ГАЛИМҖАНГА

Уф та пуф килә Галимҗан,
Никтер борчыла гали җан.
Күзләреннән йокы качты,
Күзләрен йомса, саташты.
Йөреп чыга озын төнне,
Сагына ул, беләм инде.
Тәрәзәгә атланмакчы,
Йөрәгенә ял тапмакчы.
Түшәгендә ята аунап,
Ята аунап, түшәм санап.

Йә Ходa, калды тамактан,
Сөйләшмәс булды азактан.
— Әйтче, — дим, — кардәш, ни булды?
Саргаеп кибүең шулмы?
Тынычлык кирәк авыруга,
Ярдәм итмәс бер дару да.
— Атна-ун көн килгәнемә,
Хәлем белми җиңгәң менә.
Аламамы-саламамы,
Ире бит мин, кара аны!
Борынын күтәрсә артык,
Төшереп килермен кайтып.
— Нигә күптән сөйләнмәскә?
Пүчтәк эшне көйләмәскә.
Үтсә үтәр бер-ике көн,
Саклап торыр ишек төбен.
...Килде җиңги оча-калка.
Колагында алтын алка.
Әллә ничә бармагында
Нурлар уйный балдагында,
Йөзе балкый, көлеп тора,
Карты өчен үлеп тора.
Ул сые, күчтәнәчләре,
Җимеше, пешкән ашлары...
Гөрләшеп сүзләре бетми,
Тиз генә кайтып та китми.
Дәрт, төс керде Галимҗанга,
Бәхет килде гали җанга.
...Мин язып салган хатымны
Алып укыган хатыны.

Гыйбрәтле сүзләр бар анда,
Тик әйтмәгез Галимҗанга.
«Миннән сиңа чук-чук сәлам.
Галимҗаның нинди адәм?
Ияреп йөри артымнан,
Чистый кикердем картыңнан.
Чибәрем, ди, идеалым син! —
Үбеп алды, оялдым мин.
Характерын күрдем инде,
Бүлмәсенә кермим инде.
Ертып ташларсың хатымны,
Аздырма шулай картыңны!»

## ИРКӘ КЫЗЛАР

Иномаркаларда килә
Мәктәпкә иркә кызлар.
Аларның бит этиләре
Корольләр яки тузлар.
Колакларында алканың
Ниндиләре генә юк.
Бармакларында балдаклар
Ялтырыйлар ялт та йолт.
Иртән торып җитешмәгәч,
Күз ясыйлар дәрестә.
Оценка таләп итәләр
Кул тидермәгән эшкә.
Күз кабаклары кызларның
Каралай янган кебек.

Курчаклары алларында —
Сүзләрем ялган түгел.
Мәктәпме бу, театрмы,
Нәниләр бакчасымы?
...Җитте инде. Язмыйм бүтән.
Мин кызлар сакчысымы?!

## ХИМИК МАТДӘ

И Ходаем, нинди генә
Химик матдә эшләнми.
Кешелек матурлык серен
Әле һаман чишәлми.

Көн юк мескен керфекләргә,
Кашлар, күз кабагына.
Иреннәрнең интеккәнен
Белә бер алла гына.

Ә чәчләрне көйдерәләр,
Буйыйлар ал, яшелгә.
Күпләр, хамелеон кебек,
Чын йөзен дә яшерә.

## ТӨТЕН САНАП

Өйдән өйгә төтен санап,
Ир-ат йөри эзләнеп.
Әнә берсе кайтып килә
Дүрт мүкәйләп, тезләнеп.

— Ир-атларым, кайда соң сез?
Күренмисез урамда.
— Без теге дөньяга күчтек,
Сәбәбен син сорама.
Ирләреннән ятим калган
Хатыннар, ни уйлыйсыз?
Өйдән өйгә төтен санап,
Эзләнүдән туймыйсыз.
Гүзәл затның кайберсенә
Әллә күз тиде микән?
Киң урамнарны тар итеп,
Атлыйлар алпан-тилпән.

## АЧЫП КУЙ ИШЕКЛӘРЕҢ

Ашыкма әле ташларга
Иске киемнәреңне.
Хәтердә яңа чагында
Киеп сөенгәнеңне.

Бүген булмаса, иртәгә
Кирәге чыгуы бар.
Яңа алган киемеңнең
Охшамый куюы бар.

Иске яңаны саклый дип,
Бар минем ишеткәнем.
...Онытма иске дусларың,
Ачып куй ишекләрең.

ТАКМАКЛАР

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява,
Өй түбәсе шиферга.
Юләр булсаң да ышанма
Им-том белән сихергә.

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Чубайс.
Утка салсаң, утта янмый,
Судан коры чыга ич.

Ашаганым аш түгел,
Кашыганым баш түгел.
Авыру Ельцинны сагынып,
Көн дә елыйм яшь түгеп.

Уф, йөрәгем тыпырчына
Күкрәгем читлегендә.
Көн дә туйганчы ашарга
Пенсиям җитми миңа.

Күлмәккә акчам җитмәгәч,
Сатып алдым ямаулык.
Пенсионерның акчасы
Кара песи яларлык.

Хамелеонның гәүдәсеннән
Озынрак икән теле.
Ходаем, шундый тел бир, дип
Гайбәтче теләк тели.

# ПОЭМАЛАР

## УТЛЫ ЕЛЛАРДА

1

Егетләрне күрше-күлән
Озаттылар сугышка:
«Фашистларны җиңеп, язсын
Кайтырга тын тормышка».
Теләделәр теләкләрнең
Изгесен, матурларын.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә
Үптеләр батырларын:
— Сез үлемнән курыкмагыз,
Сездән курыксын үлем.
Сез сакламый, кем сакласын
Бердәнбер Туган илен.
Исән кайтыгыз, балалар,
Хатлар язып торыгыз.
Кайгырмагыз безнең өчен,
Без исән-сау булырбыз.
Биш яшьтәш китте яуларга —
Егерме бишенчеләр.
Бер җан булып, гыйшык тотып,
Авылда яшәүчеләр.

Ватан өчен утка керер
Авылым батырлары.
Җиңеп даннары кайтырмы,
Үзләре кайтырлармы?
Бергә киттеләр сугышка,
Тик бергә кайтмадылар.
Һәлак булды:
Рәфкать, Рәвил, Нәҗип,
Илемне сатмадылар.

2

Озатты яуга улларын
Туган авылым — Истәгем.
Чиккән яулык бүләк итте
Гәзизә — җан кисәге.
Очып килеп, Галиханның
Үбеп алды битеннән:
«Исән-сау кайт, вәгъдәбезгә
Беркайчан тап төшермәм.»
Шыгырдатып ак карларны
Кузгалдылар чаналар.
Иярде чана артыннан
Елгыр бала-чагалар.
Басып җибәрде Галихан
Тальян басмакларына.
Моң таралды, сәлам булып,
Туган якташларына.
«Баламишкин», «Шахта» көе —
Халыкның яратканы;

Уй-хисләрне яңартканы,
Кайгыны таратканы.
Җырлап урам әйләнделәр.
Җырлары да җырлары.
Күңелемә сеңеп калды
Шул җырларның моңнары:
«Басу капкасын чыккач та
Уңга киткән юл булыр.
Исәр җилләр, чыгар кояш,
Бездән сәлам шул булыр.
Ал да булырбыз әле,
Гөл дә булырбыз әле.
Әйләнербез дә кайтырбыз,
Бергә булырбыз әле.
Түтәлләргә чәчеп куйдым
Чәчелмә суганнарым.
Чәчелмә суганнар кебек
Чәчелдек, туганнарым.»

3

Яңавыл стансасында
Шау-шу, халык ашыга.
«Төялегез! — ди командир, —
Вагоныгыз каршыда.»
Озакламады паровоз,
Кычкырды сузып-сузып.
Текелдәде тәгәрмәчләр,
Рельска сугып-сугып.
Ярый иңенә ачканнар
Йөк вагоны ишеген.

Йөрәгем чымырдап китте
Иркәм тавышын ишетеп:
— Га-ли-хан, о-ныт-ма!
Җиңеп кайт!
Безнең яшьләрнең поездда
Йөргәне булды микән?
Кама, Нократ, Идел суын
Күргәне булды микән?
Поездга каршы йөгереп
Килә шәһәр, авыллар.
Яңавыл, Карман, Сарапул,
Күптән артта калдылар.
Йөрәкләремне өздерә
Паровоз тавышлары.
Озын юллар, карлы җилләр
Арттыра сагышларны.
Без чыгып киттек авылдан
Кырык өчнең гыйнварында.
Өйрәттеләр сугышырга
Тодцкий лагеренда.
Корал таратып бирделәр
Белгород шәһәрендә.
Тиздән сугышка керәбез,
Монда без яшьләр генә.
Харьков юнәлешендә бер
Траншеяга урнаштык.
Дошманнар ут яудыралар,
Калкытыр хәл юк башны.

4

Күзгә төртсәң дә күренми,
Шундый кара төн иде.
«Һөҗүмгә» дигән команда
Тәмам ярсытты мине.
Яктырткыч ракета атып,
Өскә киләләр туры.
Пулеметтан ата-ата
Дошманның бүлдек юлын.
Черепанов — яшь командир,
Көчле, гайрәтле егет:
Хәшәрәтләрне сытыйк, ди,
Кандала сыткан кебек.
Кызганыч, ике иптәшем
Һәлак булды алышта.
Командир солдат Заһитне
Төбәп куйды алмашка.
Ул минем якташым икән,
Заһит Вәлиев була.
Бәләбәй районыннан,
Кыю, ут чәчеп тора.
Заһит әйтә: «Сиңа немец
Пулялары тими, — ди. —
Гел второй номер үлә,
Әҗәл сиңа тими, — ди. —
Син, пулеметчы Галихан,
Илебезне данлыйсың.
Дошман атканчы атасың
Һәм тидерми калмыйсың.

Әкият батыры кебек,
Син кыю егет икән.
Мин дә синнән калышмам, дип
Яшәргә өмет итәм.
Имеш, бер татар мәргәне
(Дөресме ул — кем белгән)
Илле адымнан чебеннең
Уң күзенә тидергән.»
«Мактамачы, Заһит туган,
Әллә күз тидерерсең,
Дискаларны заряжать ит,
Соңыннан көлдерерсең.»
Алдагы чүмәләләргә
Аткан саен ут каба.
Кая керер тишек тапмый,
Дошманнар үлеп кала.
Ата-ата уттай кызды
Пулеметның көпшәсе.
Шундый чакта туктап калды,
Нихәл генә итәсе!
— Туктатма, ат! — дип кычкыра
Командир, әмер биреп.
Ябырылып килә фашист,
Үзләрен өстен күреп.
Карасам, патронникта
Патрон калган яньчелеп.
Пулемет тотынгач эшкә,
Кырыла фашист чәчелеп.
Исәннәре йөгерә, кача
Төрле якка сибелеп.

Шулчагында сул аягым
Сызлый башлый өздереп.
Дустым Заһиткә дә дошман
Пулясы килеп тигән.
Яшь лейтенант Черепанов
Ярдәмләшергә килгән.
Яраларны бәйләште дә
Әйтте: «Монда калмаска.
Тылда көтә сезне бүләк,
Шуышыгыз санчастька.»
Кулларыбызны кысты да
Озатты безне тылга.
Сугышта һәрвакыт шулай
Көтелмәгән хәл туа.

5

Ай ярымда госпитальдә
Дәваланып чыкты ул.
Яңа көч, яңа дәрт белән
Үз частена тотты юл.
Штурмлаучы отрядка
Билгеләделәр аны.
Тагын да ул пулеметчы,
Отрядның шаулар даны.
Пулеметтан ата-ата
Ул чыга каршы ярга.
Безнекеләр көчле булгач,
Көн бетте фашистларга.
Днепрны кичүләре
Сугышта җиңел түгел.

Кайдан гайрәт алганнар, дип
Әле дә уйлый күңел.
Бер авыл өчен сугышта
Яраланган Галихан.
Санҗар дигән госпитальдә
Ике ай яткан гали җан.
Терелгәч тагын сугышка,
Донбасска, запас частька.
Озак тотмадылар анда,
Исән-сау булгач башлар.
Мәскәү, Ленинград аша
Фин сугышына китте.
Үзе өйрәнгән һөнәре —
Ул тагын пулеметчик.
Кече лейтенант Шуковин
Аны күреп алды да:
— Комсомолга керәсеңме?
Язасыңмы гариза?
Ул комсомол секретаре,
Комсомол бул, дип кыстый.
Комсомол билеты биргәч,
Галинең кулын кысты.

6

Өч оборона сызыгын
Җимерделәр финнарның.
Моннан да каты сугышны
Булмагандыр күргәне.
Маннергейм линиясе —
Ныгытмасы дошманның.

Кидермәкче булды явыз
Тимер-бетон кыршавын.
Әйтерсең, вулкан атылды,
Күк күкрәп, купты давыл.
Кара төтен, кургаш болыт,
Сулыш алуы авыр.
Самолет, артиллерия,
Туплар аткачтын шаулап,
«Ура» кычкырып, алдылар
Выборг шәһәрен яулап.
Бомба шартлагач, Галихан
Туфрак астында калган.
Дуслары, табып, солдатны
«Кабер»дән йолып алган.
Ленинград госпитале.
Җан бирерме шушында?
Өч көн, өч төн кузгалмаган,
Килә алмаган һушына.
Көчкә аңына килгән ул
Дүртенче көнне генә.
Рәхмәт хәрби табибларга,
Терелтми кемне генә.
Белмим, кем бәхетеннәндер:
Галихан солдат исән!
Үлем турындагы хәбәр
Хак түгел, ялган икән.

7

— Солдат, — дигән военврач, —
Кайтарабыз иленә.

Синең өчен бетте сугыш,
Савыгырсың өеңдә.
Шул минутта яшь егетнең
Йөрәге типкән шашып:
— Солдат урыны сугышта,
Нәрсә эшләрмен кайтып?
Нәрсә әйтер әти, әни?
Нәрсә уйлар Газизә?
Эшләп ашарга өйрәнгән,
Өйрәнмәдем әзергә.
Юаталар иптәшләре:
— Кайгырасың юкка, — дип. —
Кыйнама әле җаныңны,
Уфылдама, тукта, — дип. —
Тынычланып ял итәрсең
Туган иленә кайтып.
Туган җиреңнең һавасы
Барча дарудан артык.
Дуслары сүзен куәтләп,
Әйтте икенче егет:
— Исән калганыңа сөен,
Ник төштең әле җебеп?
Аякларың хезмәт итәр
Бар гомереңн буена.
Өйләнеп куй бер матурга,
Чакыр безне туеңа.
Дәррәү көлеп алдылар да
Тынып калдылар аннан.
Шомлы уйлар яугирләрнең
Күңелен яулап алган.

Һәрберсе сафка басарга
Көчләрен тупламакчы.
Илдән сөреп, фашистларны
Өнендә тукмамакчы.
Тукмарлар авыл, каланы
Ваткан, яндырган өчен.
Сабыйларны йортсыз, җирсез,
Ятим калдырган өчен.

8

Вагоннан төште яшь солдат,
Каранып як-ягына,
Түшендәге медальләре
Көн нурында чагыла.
Дулкынлана-дулкынлана
Кемнедер эзләде ул,
Өзелеп сагынуына
Ничекләр түзгәндер ул.
Яңавылда кем йөресен,
Уттай урак өстендә.
Үләрен дә белми халык,
Тырыша бар көченә.
Җәяүләп кайта Галихан
Аэропорт, кырлар аша.
Авыл якынайган саен,
Күңелдә уйлар таша:
Ничек каршылар якташлар,
Күренерме Газизә?
Йөрәккәемә Истәгем
Якын да ул, газиз дә.

9

Кайтып озак ял итәргә
Мөмкинлек бирмәделәр.
Хәл-әхвәлен сораштырып,
Бригадка димләделәр.
«Тырышып эшләгән идең
Киткәнче дә сугышка.
Әйтсәм әйтим, — ди рәис, —
Бригадир син тумыштан.
Колхозда эш җиңел түгел,
Җигәбез үгез, сыер.
Ашау ягы да нечкәрде,
Эшләве авыр булыр.»
«Сугышта да авыр иде,
Җиңдек явыз дошманны.
Эш тә калмас эшләнмичә,
Җәлеп итсәк дусларны!»

10

Зифа буйлы яшь егетне
Яратып өлгерделәр.
Сылу кызлар читләп кенә
Хисләрен белдерделәр.
Ике яшь йөрәк очрашты
Сосланнар арасында.
Сикереп менде Газизә
Бригадир арбасына.
— Сагындым, — диде Галихан
Билләреннән кочаклап.

— Чү, күрерләр, — дигән булды
Газизә әдәп саклап.
Күзгә төн корды пәрдәсен,
Белгәндәй яшьләр уен.
Арыш басуы өстенә
Йолдызлар сипте нурын...
Кыңгыраулы атлар килә
Тузаннарны туздырып.
Сөйгән ярлар кайта парлап,
Тарантаска утырып.
Җыелып халык каршылый
Тулы ачып капканы.
Килен төшә, Галиханның
Җан сөйгәне, аппагы.
Кәләшен күтәреп алып,
Бастырды ак мендәргә.
Бал-маен да каптырдылар,
Күз тимәсен чибәргә.
Гармунчылар гармун уйный
Тартып-сузып күреген.
Киленнәрнең матурлыгы
Биегәндә күренер.

11

Галихан — тырыш, акыллы,
Сабыр, гадел бригадир.
Бригадасы алга чыкты,
Җитәкләгәч уңган ир.
Рәис итеп сайладылар
Колхоз җыелышында.

Шундый зур яңалык булды
Фронтовик тормышында.
Кызганыч, яугир Галихан
Иртә китте дөньядан.
Сугышта алган яралар
Сызлаган, һич тынмаган.
Хәтердә, авыл советын
Җитәкләде күп еллар.
(Ул дәверләр истәлекле,
Әйтсәм әйтим, тук еллар.)
Без бит туган Җир-Ананың
Үги баласы түгел.
Коллыктан коткарды халкым,
Европаны кан түгеп.
Җиңүнең кадерен белеп
Яшәсен килер буын.
Күз карасыдай сакласын
Яугир нәсел-ыруын.
Сугыш китергән газаплар
Йөрәкне ялмап тора.
Истәлекләр буыннарның
Чылбырын ялгап тора.

## МӘХӘББӘТКӘ МӘДХИЯ ЯКИ ҮЗ ТИҢЕҢНЕ ТАП ИКӘН

1

Якын дустым, атын бәйләп,
Кашавайдан төшерде.
Һич тә ышанасы килми:
Өнемме бу, төшемме?

«Кызым» дип каршы алдылар
Кадерле эткэм, энкэм.
— Төкле аягың белән кер,
Оялып торма, бэбкэм.
Чишен, кызым, чэй эчэрбез,
Самавыр кайнап тора.
Кыз алу, кияүгэ чыгу —
Электэн калган йола.
Алдан кисэткэн булдым шул
Әйтмэгезче килен, дип.
Яшь чагында «килен» диеп
Әйттерэсе килми бит.
Соңыннан гына аңладым,
Ялгышканмын ул заман.
Әйтсэлэр «килен», «кияү» дип,
Шатланып, телсез калам.
«Килен», «кияү» булулары
Бэхет бит ул, туганнар.
Кешенең кадерен белеп,
Гөрлэп яши уңганнар.

2

Көтмэгэндэ без таныштык
Еракта Яңавылдан.
Университетка кергэн ул да
Миннэн соң ике елдан.
Мэрмэр баскычларга басып
Өченче катка менэм.
Шунда мине көтеп торган
Ике матур кыз күрэм.

Мин туктадым. Исәнләштек.
Яңавылдан килгәннәр.
Берсе Люба, берсе Лена,
Ситса күлмәк кигәннәр.
Күзләреннән нур агыла,
Берсеннән-берсе чибәр.
— Әллә кайтып китик микән?
Бигрәк сагындык, — диләр.
— Күнегерсез әле, — димен, —
Кирәк, кызлар, түзәргә.
Якын дуслар да табылыр,
Нигә өмет өзәргә?
Шул кызларның бүлмәсенә
Еш кына барып йөрдем.
Үзен тыныч тотканга мы,
Любаны якын күрдем.
Аннан китте яратышу
(Мине гафу итегез).
Мәхәббәтнең җәтмәсенә
Уралганбыз икебез.

3

Казан Кремле янында
Ашханәдә туйладык.
Күңелле үтте туебыз,
Уйнап-көлеп туймадык.
Студент халкы дәртле ул,
Җыр да, бию дә булсын.
Балкабзый кебек гармунчы
Сыздырып уйнап торсын.

Өстәлләр сыгылып торды
Туебыз ашларыннан.
Иртән Казан урамыннан
Йөрдек гармунга җырлап.
— Туктама, уйна, җаным, — дип, —
Алдылар сорап-сорап.
Трамвайда, тартып-сузып,
Гармун уйный Балкабзый.
Татарлар да, руслар да
Тыпырдатып, «асса», ди.
Гармунчыга әйтә берсе:
— Шәп уйнатасың, малай.
Икенчесе: «Мы попляшем,
Сербияночку давай!».
Аякка басты бар кала
Балкабзый моңнарыннан.
Дәртле көйләр туып торды
Гармунчы кулларыннан.
Дөньябызны онытканбыз,
Поезд кузгалып киткән.
Вагонга чак-чак өлгердек,
Торып калырбыз икән.

4

Бөтерелә сылу кызлар
Балкабзый тирәсендә.
Үзе гашыйк булды микән
Кызларның берәрсенә?
Сораштылар, ул кем, диеп,
Әллә Уфадан килгән?

Таныштырмый булмас инде
Оста гармунчы белән.
Балкабзый — минем туганым,
Гыйлемхан атлы егет.
Яши Истәк авылында
Мал карап, иген игеп.
Казанлылар чакырдылар
Балкабзыйны кунакка:
— Калсаң, бер бүлмә бирәбез
Сиңа тулай торактан.
Өйләнерсең, туй ясарбыз,
Ризалашсаң әгәр дә.
Атлыгып тора кайтырга
Туып үскән авылга.
Туйчыларның күңеле булсын,
Уйна әле тагын да.
Тартып җибәрде гармунын,
Җанланды көмеш телләр.
Гармун моңнарын ишетеп,
Күзен ачты сөмбелләр.
Кызлар, егетләр күңелен
Яулады сихри моңнар.
Яфракларга орына-орына
Яңгырады шат җырлар.
«И икегез, икегез,
Икегезнең битегез.
Икегез дә пар килгәнсез,
Тигез гомер итегез».

5

Дустым әйтә: «Кырык елмы?
Стажыгыз зур икән.
Әллә тату яшәгәнгә
Йөзегездә нур микән?»
Сәбәбе бер: мәхәббәттә.
Ул — яшәтә, яшәртә.
Кара кайгыларны куып,
Яшен булып яшьнәтә.
Балаларның исәннәре
Күптән башлы-күзлеләр.
Кайтып булышып торалар,
Арабызны өзмиләр.
Балаларның балалары
Татлы шикәрдән, балдан.
Аллага шөкер, барсы да
Тереләр, исән-саулар.
Белем орлыклары чәчеп,
Мәктәптә үтте гомер.
Үзебезнең эшебездән
Канәгатьбез без бүген.

6

Рәшидәм (Любам) — бик оста,
Тәмле ашлар пешерә.
Мин абзарда маллар карыйм,
Тырышам бар көчемә.
Тышта бик озак булашсам,
Югалтып чыга өйдән.

— Кер инде, ашым суына,
Качып йөрмәче миннән.
Аңлыйм, хәлләремнең, «биеп»,
Янадыр табаннары.
Ял итеп, «ярый эш күп» дип,
Сөенәбез аннары.
Ул сыйлый тәмле аш белән,
Мин — тәмле телем белән.
Мактый-мактый аш ашасам,
Шифасын бик тиз күрәм.
Татулыкка ни җитә дип,
Яшәдек матур итеп.
Көнләгән булып бер-беребезне,
Йөрмәдек күңел китеп.
Кырык елда кырык тапкыр
Килдек микән тел-тешкә.
Талашырга вакыт калмый
Икең дә булгач эштә.
Эшләр тәмам хутка китте,
Кырык ел гомер иткәч.
Йөрәкләрне йорт эшенә
Парлап, текемләп җиккәч.
Синең эш йә минем эш, дип,
Тарткалашкан юк хәзер.
Пионерларча яшибез:
— Һәр эшкә дә без әзер!
Бер-беребезгә рәхмәт әйтеп,
Яшибез тыныч кына.
Мәхәббәтебез бит кайнар,
Эретер корычны да.

Рәхмәт әти-әниләргә,
Рәхмәт сезгә, туганнар.
Без бәхетле яшәсен, дип
Ак теләктә булганнар.
Таң ата да кич була, дип
Әйтүләре хак икән.
Гомереңгөрләп үтсен, дисәң,
Үз тиңеңне тап икән.
Кырык ел — ул кырык тапкыр
Күз ачып йомган кебек.
Сөю хисләрен яңартып,
Якты көн туган кебек.

# КЫСКА ХИКӘЯЛӘР

## «СУЫ ТӘМЛЕ БУЛЫР»

Әнгам Атнабаев халык арасында үзен судагы балык кебек хис итә иде. Рәхәтләнеп сөйләшә, көлдерә, шаяра, үзе дә кешеләрне тыңлый белә, четерекле сораулар биреп куя. Мәктәпләргә дәртләнеп, рухланып бара торган иде һәм укучыларга хикмәтле, уйланырлык, фәнчә әйтсәк, проблемалы сораулар бирергә яратты. Менә шундый сорауларның берсе:

— Нинди елга экваторны ике тапкыр кисеп чыга?

Балалар тиз генә җавап бирә алмагач, карта, атласлардан эзләргә кушып:

— Үзегез эзләп тапкан елганың гына суы тәмле була ул, —дигән.

Белмим, ул елганың суын укучыларның берәрсе эчеп карады микән, юк микән, әмма аның исемен онытмыйлардыр, мөгаен.

## БАЗАРДА

Базарга бүген дә ит бик күп килгән. Галимулла да, башкалар кебек үк, итен ваклап, киштә өстенә тезеп куеп, үлчәвен тигезләде дә, алучыларны көтә башлады. Көтә-көтә көтек булып бетсә дә, аның итенә игътибар итүче булмады. Бер мәлне авылдашы килеп исәнләште дә:

— Итең бигрәк ябык икән бит, абзыкаем, кып-кызыл, күн кебек, ничегрәк сатарсың микән, — дип Галимулланың болай да ярал күңеленә тоз салды. Авылдашының сер бирәсе килмәде, эре генә җаваплады:

— Вакытында ашаганмы ул, мәхлук, су эчкәнме, астын тазартучы булганмы аның. Корсагына кадәр сазга батып, ашарга-эчәргә сорап бакырып абзарда ятты шунда. Башак бирергә оны, ашатырга печәне, саламы җиткелекле булмады.

— Алай итеп ит сатып булмый ул. Итеңне мактаган бул, мылкынганчы ашаттым, фәлән-фәсмәтән диген, — дип киңәш биреп китте авылдашы.

Галимулла итне алучы булырмы, юкмы дип кайгырып торганда, бер яшь кеше килеп:

— Агай, итең тәмлеме, симезме? Күпмегә сатасың? — дип сорашкач, Галимулла җанлана төшеп:

— Симез булмый ни, симез булыр шул! — диде. — Ашаган, ял иткән мал симез була

инде. Аны җигеп җир сөргәннәрме, урманда бүрәнә тарттырганнармы, утын-печән ташыганнармы, иярләп атланып йөргәннәрме!

Мондый хикмәтле сүзләрне ишеткән кешеләр, чиратка тезелеп, абзыйның итен өләшеп алып бетерделәр.

## ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

— ...Безнең авылда матур, тату, үрнәкле гаиләләр аз түгел. Минем күршедә дә бик тә уңган, сөйкемле, бер-берсе өчен үлә язып торган әби белән бабай яшәде, — дип сөйләп китте танышым. Аның, һич көтмәгәндә, кеше гаиләсе турында сүз башлавы мине гаҗәпләндерде. Сагая төшеп, игътибар белән тыңлап тора башладым. Кордашымның үзе сөйләгән күршеләре турындагы истәлеге аның күңел түрендә кадерләп саклануы бәхәссез иде...

— Бабай алты дистәсен тутыргач та, эштән туктыйм, димәде. Ул гомере буена колхоз умарталыгында бал кортлары карады. Авыл халкы аны, яратып, «бал бабай» дип йөртте. Һәркөнне иртән, атын җигеп, көтү белән бергә карт бакчага эшкә китә, кич эштән көтү белән бергә кайта. Ә карчыгы инде — «бал әби» — һич кенә тик тора белми, йөгереп эшләп йөри: әле кош-кортларны ашата, әле ишек алларын, капка төпләрен кат-кат себерә. Нигә кат-кат себергәндер инде, мәрхүмә? Бер бөртек яфрак

та, тузан да төшермәде. Бөтен җире көлеп, «ялт» итеп тора. Үзе дә, карты да бик чисталар, кием-салымнарына кер төшми... Алай гына да түгел әле: әллә ничә тапкыр капка төбенә чыгып, урамда йөргән малайларга:

— Бал бабагызның кайтканы күренмиме, балакайларым? Тегендәрәк барып карап килегез әле, — дип ярдәмләшүләрен үтенә. Кат-кат ишек алларын карап чыга, балкытып чистарткан җиз самавырына күмер сала — пар бөркеп, чыжлап торсын. Комганга җылы су салып, чиста сөлге элеп куя.

Бал бабайның авыл башыннан күренүе була, ул шатланып, капкасын иңенә ачып, картын көтеп тора.

— Исән кайттыңмы, картым, — дип елмаеп каршы ала. Картның кәефе көр, күңеле күтәренке. Чөкердәшеп сүзләре бетми.

Элек әнә ничек иде бит дөньялар!

Ә хәзер бөтенләй башкача. Үзгәргәч тә үзгәрә икән заманалар.

Җиңел машина, өстәвенә, «иномарка» әле ул, капка төбенә кайтып туктыйсың. Кая ул сине капка ачып, исән кайттыңмы, диеп, сөенәсөенә елмаеп каршы алу! Юк ул, көтәсе дә, өмет итәсе дә юк. Хатын, йоклап, шешенеп беткән, ашы суынган, электр чәйнегенең суы калмаган, балалар, таң атса да, һаман кайтмаган, кайдадыр күңел ачалар.

Сәбәп нәрсәдәдер инде, кем белсен...

...Шулвакыт танышымның хатыны, авызын зур ачып исни-исни, капкадан килеп чыкты.

— Туйган инде синнән, сасы аракы, суган исеннән, — диде ул, ачуланып. — Бал бабай, дигән буласың, аңардан ичмасам, болын чәчәкләре исләре генә килеп тора иде. Эштән дә вакытында кайта, вакытында китә торган иде. Синең кебек, югалып йөри торган гадәте юк иде...

Бәлки бөтен хикмәт тә нәкъ менә шул болын чәчәкләре исендәдер, кем белсен...

## КЫЧКЫРА — ТАВЫШЫ ЧЫКМЫЙ

Галимә әби ишек алдында үзалдына сөйләнеп, тавыкларын туйдырып, әтәчен күзәтеп йөргәндә күршесе килеп керде.

— Яшь әтәч калдырган идем, күрше. Болай гәүдәсе дә ким-хур түгел инде, төсе-башы да килгән, тавыкларны да куандырып кына тора. Тавыкларын кара син аның, яныннан читкә китмиләр дә, яраталар инде. Тик әтәчнең бер кимчелеге бар шул, кычкыра — тавышы чыкмый. Җилпенә-җилпенә авызын ача, кычкырган булып кылана инде. Тавышы чыкмый шул. Әллә тамагына берәр нәрсә утырган?

Шулчак әтәч киртәгә очып менде дә, канатлары белән кагынып, кычкырып җибәрде.

— Әнә инде, күрше, — диде Галимә әби, — кычкырган булды, тавышы чыкмады. Нишләтергә инде моны?

Күршесе, бер әтәчкә, бер хуҗа карчыкка карап, аптырашта калды. Әтәч тагын кычкырып җибәрде. Шунда гына күршесе аңлады: Галимә әбинең үзенең колагы каткан икән.

— Әтәчеңнең тавышы бөтен авылны яңгырата, үзең ишетмисең, — диде күршесе, Галимә әбинең колагына кычкырып.

## «ПРОЩАЙ, ИМАМЕТДИН!»

Истәк авылы кешеләре әлегә кадәр шушы канатлы әйтемне онытмыйлар, сөйләшкәндә үзләре дә еш кулланалар һәм борын астыннан гына елмаялар. Ачулы булсаң, шул сүзләрне ишетү белән бөтен ачуың тарала һәм күңелләрең күтәрелеп китә.

Авылның Имаметдин исемле кешесе, бәләкәй чанасына утын төяп, урманнан кайтып килә икән. Ах-вах килеп переездга барып җитсә, пассажир поезды килеп туктаган. Вагон ишеге ачылган. Игътибар белән караса, каршысында хәрби кием кигән Сталин басып тора икән. Ул фуражкасын салып исәнләшкән дә японнарга каршы сугышка баруы турында әйткән, имеш, японнарның көне санаулы гына калды, дип өстәгән. Поезд кузгалып киткәндә Сталин, уң кулын болгап:

— Прощай, Имаметдин! — дип кычкырган, янәсе.

Белмим, ул юлдан Сталин үткәнме-юкмы, «уф алланы» тартып кайтучы авылдашымның исемен шул арада чалып алыуын әйт әле син. Сугыш елларында тормыш никадәр авыр булса да, кешеләр тормышчан, өметле һәм кызыклы мәзәкләр уйлап тапканнар һәм шулар белән кеше күңелен күтәргәннәр, үзләренең исемнәрен дә мәңгеләштергәннәр.

## «САЛКЫН ИТ»

Хәзергегә караганда, сугыш елларында кыш бик салкын һәм кар күп була торган иде. Халыкның өсте юка, аякта чабата, ат арык. Шулай да район үзәге Яңавылга базарга барырга кирәк. Ә базар бик иртә башлана, өлгерми калуың ихтимал. Кичтән Истәккә килеп кунып, иртәнге караңгыдан торып китсәң, базарга һичшиксез өлгерәсең. Бездә шулай кунып калучыларны «йөкчеләр» дип йөртәләр иде.

Шулай беркөнне йөкчеләр Харис бабайларга кунарга керәләр, чәй эчәргә утыралар.

— Хатын, кунакларга салкын ит керет, салкын ит, тамакларын туендыр, — дип кычкырып әмер бирә икән карт. Ә хәләл җефете салкын ит түгел, ә бәрәңге генә куя табынга.

Тышка чыккач юлаучылар үзара сөйләшәләр икән:

— Харис бабай юмарт та соң, карчыгы саран шул. Карчыгы тәки салкын итне кертмәде бит.

Алар, әлбәттә, Харис бабайның бәрәңгене «салкын ит» дип атавын аңламаганнар. Сугыш елларында бәрәңге итне дә, ипикәйне дә алыштыра иде.

## «ЭССЕ МУНЧА, СУЫК ТАШ»

Юлаучылар өйгә кергәндә, Харис бабай изүләрен ычкындырып, битен, муеннарын сөлге белән сөртеп, хәле бетеп, эссе мунчадан чыкканлыгын төшендереп утыра икән.

— Күптән түгел генә мунчадан чыктым. Мунча эссе, ташы гына суык. Хәзер үк барыгыз, югыйсә суыныр. Барыгыз, барыгыз, рәхәтләнеп керегез, — дигән хуҗа. — Әнисе, сөлге биреп җибәр кунакларга.

Чыксалар — мунча, абзар юлларын көрт басып киткән. Арадан берсе өйгә кире кергән:

— Харис абзый, мунчаны да, мунча юлын да кар басып киткән.

— Кыш көне кар ява инде ул. Әле сез килер алдыннан гына бик усал буран булды. Аптырап тормагыз, көрәкләр алыгыз да мунча юлын көрәгез.

Элгәре, ут чыгудан куркып, мунчаны өйдән ерак салганнар. Юлаучылар, кар көрикөри тирләп пешәләр. Мунчаның ишеген тарталар — ача алмыйлар. Ишек ябышып каткан. Типкәләп тарта торгач, ишек ачылып китмәсенме. Мунчага кереп, пыскый яндырып кара-

салар, мунчаның стеналары шәрләнеп беткән, ташлары боз чәчеп утыра икән.

Өйгә кайтып, хуҗага:

— И Харис агай, кешене шулай алдарга ярамас иде. Кар көрибез дип янып пештек, күлмәкләребез лып-лычма булды, — дип әйткәннәр, имеш.

— Юк, туганнар, мин сезне алдамадым. Башта ук мин сезгә эссе мунча, суык таш дип әйттем бит. Мунчасы эссе булмаса, тирләр идегезмени? Сөртегез тирләрегезне, минем тастымалны да алыгыз.

## «ЯМАУЛЫККА ДА ҖИТМӘДЕ»

Тәтешле авылында бик ярлы Гайса исемле карт яшәгән, ди. Алмашка чалбары булмагач, кия-кия аның бер дә рәте калмаган. Инде ничә тапкыр катлап-катлап ямаган чалбарын тагын ямарга тотынса, ямаулык та тапмаган. Ничек кирәк акча җыештырып, кибеттән ике метр материя сатып алган да, өенә кайтып, чалбарын ямарга тотынган. Ямаган да ямаган, ямаган да ямаган, ямый торгач, моның ике метр тукымасы җитми дә калган. Шуннан аптырап сөйләнә икән:

— Ике метр мануфактура алган идем, ямаулыкка да җитмәде, чалбарым тегелеп тә бетмәде.

Тыңлап торган иптәше:

— Мануфактура түгел, баш җитмәде, дигән. Башың җитсә, өр-яңа чалбарлы була идең, ике метр материал сиңа тулып узган иде, — дип әйткән, ди.

## Эчтәлек

Үзем турында сүзем (автобиографик белешмә) . 5

*Шигырьләр*

Ягез, авыз итик . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Китмәс инде . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Илкәем бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Башкортстан . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Куанам мин . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Кошлар кайта . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Истәгем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Без — Яңавыл яклары . . . . . . . . . . . . 15
Эзлим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Җырлар очырам әле . . . . . . . . . . . . . 17
Җәйге таң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Чишмәкәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Яратам мин туган авылымны . . . . . . . . 20
Нурлы иде яшьлегем . . . . . . . . . . . . . 20
Яңавыл плюс Казан . . . . . . . . . . . . . 21
Китмәгез, кызлар . . . . . . . . . . . . . . . 22
Онытмагыз хатлар язарга . . . . . . . . . . 23
Сагынам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24

Сүзләр — гәрәбә . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Ничек китим . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Күңелем чишмәләре . . . . . . . . . . . . . 26
Каймаша . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Сагындым Истәгемне . . . . . . . . . . . . . 28
Күтәреләм зәңгәр һавага . . . . . . . . . . . 29
Теләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Көзге гөлләр . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Карчыга кунган икән . . . . . . . . . . . . . 31
Җил ял итә . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Куркам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Ак карлар . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Өзәм инде . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Яз нурлары уйнаганда . . . . . . . . . . . . 35
Сөеп уяталар аналар . . . . . . . . . . . . 35
Юлга чыксам . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Нигә, әткәй, моңландың . . . . . . . . . . . 37
Әнкәй пешергән икмәк . . . . . . . . . . . . 38
Ник киттең? . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Сагынам сине, әнкәй . . . . . . . . . . . . 40
Бергә үтте гомер юлларыбыз . . . . . . . . . 41
Гомер юлдашым Рәшидәгә . . . . . . . . . . 41
Сиңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Резедага . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Улыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Лилиям . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Өй тора көлеп кенә . . . . . . . . . . . . 46
Олы бәйрәм, кече туй . . . . . . . . . . . . 47
Оныгым Илмирәгә . . . . . . . . . . . . . . 48
Исем туе . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Котлы булсын . . . . . . . . . . . . . . . 50
Гүзәлгә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Оныкларым килгәндә . . . . . . . . . . . . 51

Уртак бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Газимә апама . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Нәгыймә апа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Имән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Вәсил Хәбисламовка . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Вәнзир Галинга . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Изге җанлы Әлфия . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Авыл баласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
«Өмет»кә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Ахирәтем «Кызыл таң» . . . . . . . . . . . . . . 60
Мәктәбемә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Укытучыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Киләчәккә карыйм өмет белән . . . . . . . . . . 63
Исә яңарыш җилләре . . . . . . . . . . . . . . . 63
Көткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Яңа ел сәгате суга . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Дөнья матур . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Күтәрелә кошлар күкләргә . . . . . . . . . . . . 67
Бәхет орлыклары чәчеп . . . . . . . . . . . . . . 68
«Мин — матур» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Уйлар диңгезендә . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Кеше булып калам . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Аргамаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Җиңү көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Сугыш ветераны Нәкыйп абыема . . . . . . . . 72
Һәйкәл куйыйк . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Яугир егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Солдат улым, Илнурым . . . . . . . . . . . . . . 74
Ялгыз ана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Кайда соң сез? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Пешә тора . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Хастаханәдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Әйтче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80

«Дөнья күрсәтеп өлгерде...» . . . . . . . . . . . 80
Көяләнәм кыз язмышы өчен . . . . . . . . . . 81
Иманы бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Булганы ярап тора . . . . . . . . . . . . . . 82
Газраил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Театр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Күңелеңне тотма читлектә . . . . . . . . . . 86
Килегез, шатлыкларым . . . . . . . . . . . . 88
Кара болыт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Йомгак ясыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Ярат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Биздергән тау . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
«Сугыш» уены . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Десантчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Гармун уйный кыз бала . . . . . . . . . . . 95
Соңгы кыңгырау . . . . . . . . . . . . . . . 96
Хушлашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Игенче булырмын . . . . . . . . . . . . . . . 98
Каен көч ала каян? . . . . . . . . . . . . . . 99
Терсәкне булмый тешләп . . . . . . . . . . . 100
Безнең Ингел . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Зәнфирә китап укый . . . . . . . . . . . . . 102
Икесе дә матур кыз . . . . . . . . . . . . . . 103
Сыерчык балалары . . . . . . . . . . . . . . 104
Авылга барыйк, диләр . . . . . . . . . . . . 106
Тепловоз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Көтәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Тамчылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Йолдызлар — көрәзәче . . . . . . . . . . . . 112
Күк чәчкәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Җиләкләр пешкән иде . . . . . . . . . . . . 114

Чәчәкләр утыра тын гына . . . . . . . . . . . . . . 114
Туктап торыйк, тыңлап торыйк . . . . . . . . . 115
Киңәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Җитеп килә алмасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Яннарыңа барырмын . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Мин — Яңавыл баласы . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Утта янам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Бәлки, гафу итәрсең . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Шаяру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Мәхәббәтең булса . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Ятсынма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Кайда минем мәхәббәтем? . . . . . . . . . . . . 122
Яшермә карашыңны . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Телевизор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Яшь парга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Кызлар үтеп бара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Көнләшүең үтә җилегемә . . . . . . . . . . . . . 127
Күңелләрдә яз була . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Урамда кунасыңмы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Сандугач тынган иде . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Көзге вальс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Мәхәббәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Тыңлармын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Нәфсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Бер егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Авыл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Төтен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Хәйләлә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Шунда мәхшәр вә тәмуг . . . . . . . . . . . . . . 137
Доллар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Оныткан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Йөрәге тора җилфердәп . . . . . . . . . . . . . . . 140
Җаен тапкан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

Бар инде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Өйләндем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Әти булдым мин бүген . . . . . . . . . . . . . . . 144
НЛО . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Яратам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Күзең төштеме әллә? . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Бәхет килде Галимҗанга . . . . . . . . . . . . . 148
Иркә кызлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Химик матдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Төтен санап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Ачып куй ишекләрең . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Такмаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153

*Поэмалар*

Утлы елларда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Мәхәббәткә мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

*Кыска хикәяләр*

«Суы тәмле булыр» . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Базарда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Элек һәм хәзер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Кычкыра — тавышы чыкмый . . . . . . . . . . 179
«Прощай, Имаметдин!» . . . . . . . . . . . . . . 180
«Салкын ит» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
«Эссе мунча, суык таш» . . . . . . . . . . . . . 182
«Ямаулыкка да җитмәде» . . . . . . . . . . . . . 183

Литературно-художественное издание

**Мунавир Ибрагимович ФАЗЛЫЕВ**

**СОЛОВЬИНАЯ СТОРОНУШКА**

Стихи, песни, поэмы,
короткие рассказы

*(на татарском языке)*

Нәшер итүгә җаваплы *Нил Тикеев*
Мөхәррире *Динә Морзакаева*
Бизәлеш мөхәррире *Сергей Ефименко*
Корректоры *Рәмзия Гәрәева*

